

ДУСЛЫК УЕННАРЫ

17 илдән 1,3 меңләп спортчы Казанда көч сынаша

> 2

КАДЕРЛЕ КЕШЕЛӘР

Авыл тормышын хат ташучылардан башка күз алдына китерү дә кыен

> 3

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Мин – язган чагымда гына язучы. Ә соңыннан...»

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 105 (28878) | Шимбә | 23 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

БЕР ЙОДРЫККА БЕРЛӘШЕП

Хуш киләсез!

Тагын бер атнадан Казанда Бөтендөнья татар конгрессының VIII корылтае узачак. Анда 37 илдән 1500 кунак көтәләр. Чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез нинди өметләр белән киләчәк? «ВТ» хәбәрчесе аларның уй-хыялларын белеште.

vk.com

Билгеле булганча, корылтай биш елга бер мәртәбә үткәрелә. Гадәттә, анда 1 мең делегат катнаша. Быел ул конгрессның 30 еллыгына багышлана, кунаклар саны да 500гә күбрәк. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев әйтүенчә, соңгы биш елда иң зур вакыйгаларның берсе – милли стратегияне язып, кабул итү. Хәзер аны тормышка ашыру буенча эш алып барыла. Икенчесе – Татарстанның оешуына 100 ел тулу.

– Без бу датаны республикада гына түгел, барлык өлкәләрдә дә зурлап бәйрәм иттек. Читтә яшәүче һәр татар өчен Татарстан туган якка әйләнде. Аларның горурланып кайтуын күрү – безнең өчен зур сөенеч, – диде Васил Шәйхразыев.

Очрашуда журналистлар: «Җыенда нинди проблемаларны хәл итәргә ниятлисез?» – дип тә кызыксынды. Дөресрәге, сүз мәктәпләрдә туган тел дәресләрен укыту, тел мәсьәләсе турында иде.

– Безнең каршыда проблемалар юк, бурычлар бар. Әгәр без һәр проблемага кереп китәбез икән, аннан чыга алмаячакбыз. Без бүген вазгыятьтәге хәл ителеп бетмәгән эшләрдән чыгып бурычлар куябыз, – диде Васил Шәйхразыев. – Татар мәктәпләренә китаплар җибәрәбез. 43 уку ярдәмлеге бар, шуларга сертификат алырга кирәк. Өстәмә дәресме, якшәмбе мәктәпләре, «Ана теле» программасы дибезме – алар бар. Җитәме, җитмиме, кирәкме, кызыкмы, түгелме – анысын әйтә алмыйм. Татар сыйныфлары, татар гаиләләре бар. Сүз сәгатьләр белән генә чикләнми бит. 11 нче сыйныфта татар теле имтиханнары бар, аны бирсәләр, кая барырга мөмкин... Бүген Мәгариф министрлыгы Конгресс белән бергәләп, халык тәкъдимнәренә колак салып, закон нигезендә эшләргә өйрәнергә тиеш. Җитми икән, бурычларны чишү ягын карарга кирәк.

Сахалин татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Зәкия Вәлитова Казанга киләсе көннәрен саный.

– Казан ул – безнең өчен кыйбла. Шуңа йөз тотып яшибез. Конгресс ярдәм итеп, безне бер йодрыкка берләштереп тора. Без – бик бәхетле татарлар. Ел саен ниндидер бер өлкәдә очрашабыз. Кайда бар әле андый халык? Бездә башка бер милләткә дә китаплар җибәрмиләр. Сөенечтән күзләргә яшьләр килә. Менә шушы җепләр өзелмәсен иде дип телим, – ди ул, горурланып.

Үзе ул – Чүпрәле районыннан. Сахалинга комсомол юлламасы белән өч елга дип җибәрелгән 19 яшьлек кызның бу төбәктә яши башлавына 40 ел мизгел кебек үткән дә киткән. Зәкия ханым туган нигезенә елга берничә тапкыр кайтып килергә тырыша.

– Татарлар Сахалинга беренче тапкыр 1928 елда килә башлаган. Аларны икътисадны күтәрергә дип шахтага, авыл хуҗалыгы, диңгезгә эшкә җибәргәннәр. Алар арасында хәрбиләр күп булган. Сугыштан соң 1946–1947 елларда татарлар бик күп килгән. Бүген бездә 5 меңгә якын татар яши. Тик безнең исәпләүләр буенча, алтынчы буын татарлар саны 25 меңләп булырга тиеш, – ди якташыбыз.

Анда элек бер татар мәктәбе дә булмаган, Сабан туйлары хакында хыялланырга гына калган. «Туган тел» оешмасы булдырылгач кына боз кузгалып киткән. 2006 елдан башлап ел саен үткәрелә. Балалар Сабан туе уздыру да күркәм гадәткә әйләнгән. Көньяк Сахалинда татар мәктәбе ачылган. Барлыгы 32 укучы белем ала икән. Татар теле укытучылары җитә. Соңгы елда Конгресс аша ике студентны Казан вузына укырга җибәргәннәр. Бер ел элек Тукай исемендәге этнографик музей ачылган. Татар әбиләре иске дини китаплар китерә икән. 2016 елда Сахалин белән Татарстан арасында килешүләр яңартылган. Үзгәрешләр бар бит.

Оренбург өлкәсендә 90 татар авылы бар, анда 151 мең татар яши һәм бу сан арта бара. Татар милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе Илдус Дәүләтов әнә шулай ди.

– Бездә 39 мәктәптә татар теле укытыла. Кайсында 2–3 сәгать, кайсында түгәрәктә – бер сәгать. Министрлык туган телләрне укытуга каршы түгел. Тик мәктәп директорлары гына төрле сәбәпләр эзли. Татарстан дәреслекләр белән тәэмин итеп тора. Казанда узган татар теле һәм әдәбияты укытучылары съездыннан мөгаллимнәребез канатланып кайтты. Корылтайга бездән 25 делегат барачак. Нәрсә көтәсез, дисезме? Мәктәпләрдә татар теле сәгатьләре күбрәк укытылсын иде, – ди Илдус Дәүләтов.

Делегатлар Казанга 30 июль көнне килеп җитәчәк. Бу көнне «Печән базары» заманча татар мәдәнияте фестивален тамаша кылсалар, икенче көнгә Болгар җиренә экскурсия планлаштырылган. 1 августта «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Милли Шура утырышы узачак. Анда «Идел Болгарстанында ислам динен кабул итүгә – 1100 ел. Татар дөньясы һәм ислам дине», «Милли мирас. Татар мәдәнияте: бүгенгесе һәм киләчәге», «Татар эшмәкәрлеге һәм иганәчелек», «Гаиләнең, балалар бакчасы һәм мәгариф системасының роле» һәм башка темаларга фикер алышырга мөмкин. 2 августта узачак пленар утырышта Президент Рөстәм Миңнеханов та катнашачак.

Милли Шураның яңа рәисе сайланып, яңа бурыч куелачак. Бүген Шурага 75 кеше керсә, Васил Шәйхразыев әйтүенчә, яңа составта 10–15 кеше алышыначак.

Күтәрелмәгән 8 процент

Россия банкы Директорлар советы төп ставканы күтәрмәгәндә 1,8 пунктка киметеп, 9,5тән 8 процентка калдырган. Белгечләрнең күпчелеге аның күп дигәндә 8,5 процентка кадәр генә кимүен күздә тоткан. Банк хәбәрендә билгеләп үтелгәнчә, хәзерге вакытта бәяләр үсми диярлек. Бу исә инфляциянең алга таба акрынаюына китерә. Май аенда ул 17,1 процентка кадәр күтәрелсә, июль урталарында 15,5 процентка калган. Сәбәбе март аенда кинәт кенә күтәрелгән бәяләрне йөгәнләүгә ирешүгә бәйле. Икенче яктан, кулланучылар ихтыяҗы киму дә аңа уңай йогынты ясый. Әмма икътисади эшчәнлек санкцияләр аркасында әлегә «йокымсыраганрак» хәлдә.

Балалар ышанычы

2010 елдан бирле Татарстанда балалар өчен ышаныч телефоны (8-800-2000-122) эшләп килә. Шушы вакыт эчендә аңа 360 меңнән артыграк кеше шалтыраткан. Быел беренче яртыеллыкта 20,5 мең чамасы кеше телефон аша зарын белдергән. Ә узган елда шушы чорда шалтыратучылар кимрәк (17234 кеше) булган.

Телефон аша балаларның ата-аналары, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләр күбрәк алына. Моннан тыш үсмергә карата рәхимсез караш, укудагы проблемалар, аны кыерсыту, интернет-хәтәрләргә бәйле сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр дә байтак. Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйтүенчә, ышаныч телефонына ихтыяҗ бар, шалтыратулар саны елдан-ел арта. Үсмер өчен тәҗрибәле белгечтән киңәш алу урыны бу. Аны тыңлыйлар, хуплыйлар. Бу номерга балалар гына түгел, аларның әти-әниләре, әби-бабайлары да мөрәҗәгать итә. Шулай да шалтыратуларның яртысыннан күбрәге балалар һәм үсмерләргә туры килә. Һәр ел саен әлеге телефон номерын җыючылар саны 20 процентка арта.

Ышаныч телефоны тәүлек әйләнәсе эшли. Аңа кесә телефоныннан, шулай ук гадәти телефоннан шалтыратырга мөмкин.

Арзанлы кредит

Россия Президенты ташламалы ипотека ставкасын 7 проценттан арттырмаска кушкан. Кремль сайты хәбәренә караганда, дәүләт башлыгы бу мәсьәләне 25 июльгә кадәр хәл кылуны йөкләгән. Хакимияттәгеләр әлегә, яңа йортлардан торак сатып алуга кредит ставкасы аны түләү дәверендә 7 проценттан артмасын өчен, программа шартларын үзгәртергә тиеш.

Шулай ук Владимир Путин Хөкүмәткә, кредит алучылар санын узган елдагыдан киметмәү максатында, ипотеканы ничек тә күбрәк кешеләргә бирү мөмкинлеген табу буенча 15 августка кадәр тәкъдимнәр эшләргә кушкан. Исегезгә төшерәбез: моңа кадәр ташламалы ставка 12 проценттан 9 процентка калдырылган иде. Президент Петербург халыкара икътисади форумында аны 7 процентка калдыру тәкъдиме белән чыкты. Шул ук вакытта ул программаның агымдагы ел ахырына кадәр гамәлдә булачагын әйтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Печән базары» була

30 июль көнне Казанда «Печән базары» заманча татар мәдәнияте фестивале узачак. Быел, беренчедән, ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу билгеләп үтелә. Икенчедән, Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы. Фестивальне оештыручылар социаль челтәрдәге сәхифәсендә билгеләп үткәнчә, шушы ике вакыйга «Печән базары»нда төп урынны алачак.

Фестиваль Иске Татар бистәсендә Шиһабетдин Мәрҗани урамындагы мәйданчыкта үткәрелә. Анда кәсепчеләр киштәләргә үзләренең иҗат җимешләрен урнаштырачак. Шулай ук фотозона, остаханә, чәйханәләр эшләп торачак, театрлаштырылган экскурсия, лекцияләр үткәреләчәк, музыкантлар чыгыш ясаячак, ә дизайнерлар милли кием-салымнар белән таныштырачак. Фестиваль иртәнге 9да башланып, кичке 10га кадәр дәвам итәчәк. Керү бушлай.

Вазгыять

Чикләүләр чикләмәсен

ТАТАРСТАНДА ИКЪТИСАДИ СӘЯСӘТ ХАКЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

«Әйдә, ярый»га ышанмаска, күктән төшкәнне дә көтмәскә. Социаль-икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү эшләүчедән дә, эш бирүчедән дә шуны таләп итә. Хөкүмәт йортында Татарстанда социаль-икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб һәм Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт буенча комитетының уртак утырышы узды.

Борчыган мәсьәләләргә күчкәнче, Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин җыелуның әһәмиятенә тукталды.

– Илебезгә карата кертелгән чикләүләр аркасында, республикада тиз арада социаль-икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү буенча план төзелде, штаб булдырылды. Халыкны тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итү, эш урыннарын саклап калу, бизнеска һәм халыкка ярдәм чаралары – төп бурычлар шул, – диде Премьер-министр.

Аның сүзләренчә, килеп туган вазгыять химия, резина һәм пластмасс, автотранспорт чараларын җитештерү тармакларына аеруча тәэсир иткән. Республиканың сәнәгать җитештерүе күрсәткеченең 28 проценты шул юнәлешләргә туры килә икән. Ваклап сату да кимегән.

– Икенче яртыеллыкта инвестиция проектларын тормышка ашыруга тәэсир итә торган импорт җиһазлары, запас частьлар, чимал белән тәэмин итү, логистика белән бәйле мәшәкатьләр сакланачак, – дип фаразлады Алексей Песошин. – Мондый куркыныч федераль исемлеккә кергән система коручы предприятиеләрнең яртысына – 60тан 26сына диярлек яный. Алар республика икътисадының 30 процентын формалаштыра, аларда 105 мең хезмәткәр эшли.

Яңа шартларга өйрәнеп киләләр инде. Алексей Песошин әйтүенчә, предприятиеләр Россиянең эре корпорацияләре («Газпром», «Лукойл», «Росатом» һәм «Транснефть») белән хезмәттәшлек итү турындагы килешүләр төзи, яңа кооперация элемтәләрен җайга салу буенча эш алып бара, Россиянең башка төбәкләрендәге компанияләр белән хезмәттәшлек итү буенча логистиканы үзгәртеп кора, шулай ук яңа сату базарларын эзли.

Тотрыклылык уртак тырышлык таләп итә. Утырышта катнашкан Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт комитеты рәисе Максим Топилин искәрткәнчә, санкция шартларында предприятиеләргә бары тик эчке базарга һәм чит ил товарларыннан башка ничек итеп эшләп буласын уйларга кирәк.

– Узып китәр әле, дип кенә булмый. Акча курсы бер долларга 100 сум булыр дип тә көтмик. Көткән очракта да, ике төрле план булса яхшырак. Һәркайсыбызның алга таба ничек эшләячәген күрсәткән сызымы, планы булу мөһим, – дигән фикердә ул.

Эчке базарга эшләү дигәннән, аңа ихтыяҗ булу да мөһим. Максим Топилин, барысы да элеккечә булыр дигән уйны баштан чыгарырга кирәк, ди.

– Эчке ихтыяҗның булуына гарантия кирәк. Моның өчен үзгәрешләр таләп ителә. Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР), фәнни эшләнмәләр мәсьәләләре дә мөһим, – диде ул.

Сүзгә-сүз



Анна КУЗНЕЦОВА, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары:

Психологик ярдәм буенча закон проекты әзерләнә. Ник дигәндә, бездә андый белгечләр бик аз. Халык еш кына, ярдәм алам дип, кырыгалдарлар капкынына да эләгә. Кайбер очракта гаиләләр генә таркалып калмый, гомерләр дә өзелә. Шуңа күрә сыйфатлы психологик ярдәмне тәэмин итәргә кирәк.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – «СӘЛАМӘТ» ШӘҺӘРЛӘР

Кайсы шәһәрләр сәламәтлеккә файдалы тормыш алып бару өчен кулай? «Газета.ру» Россиядә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан.

1. Сочи	40%
2. Краснодар	34%
3. Калининград	33%
...	
9. Түбән Новгород	21%
10. Казан	23%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Нәфес ялчысы

РЕКЛАМА: ФАЙДАСЫ КҮБРӘКМЕ, ЗЫЯНЫМЫ?

Аны «сәүдә әйләнешен тизләтүче» генә түгел, ә аерым бер пафос белән «алгарыш әйдәүчесе» («реклама – двигатель прогресса») дип тә атаган булалар. Азлар гына, акыллары килеп, рекламаны «нәфес ялчысы», ялтыравыклы уенчыклар аша ялтыравык тормыш вәгъдә итүче, ымсындыручы дип атарга әзер. Сатып алучыны киләкмәгәнне дә җыярга чакырып, котыртып, хәттә азындырып торучы да, сатучыны күбрәк табышка ашкындыручы да шул – реклама түгелме?

«Без сезгә чын-чынлап ярдәм итәчәкбез! Без инде миллионнарга ярдәм иттек! Проблемадан котылу өчен сиңа менә шушы шампуньны гына сатып аласы! Ул кабыкны бетерепкенә калмый, чәчне дә нығыта, аны кӳе итә – яңаларын үстерә». Шушы сүзләрдән соң сине коткарачак, бәхетле итәчәк ул шампунь гадәттә әйләндерә-әйләндерә күрсәтелә, мактала. Ул сыйфатлыдан-сыйфатлы, ул тоташ Алтай болыннарында үскән шифалы үләннәрдән генә, аны куллану сине яңа үрләргә менгерәчәк, тормышыңны үзгәртәчәк, уңыш китерәчәк. Экранда яшь, чибәр кызый пәйдә була, боргалана, матур итеп елмая, елкылдап торган, биленә җиткән чәчләрен җилпеп җибәрә, кулында, әлбәттә инде, шул тылсымлы шампунь.

Кемдер моның ишене карагач, нушкитмәле «прогресс» тоеп, кинаяк белән елмая да, аны шунда ук оныта. Ә кемнәрдер – юк. Кемнәрдер нидер сизенгән җәһәттә дә, һичбер криминал күрмичә, тәкъдимне хәтерена салып куя. Шампунь сатып алганга гына бөлмисең ич, сирәкләнгән чәчең рекламадагы шул кызныкы кебек ишелеп тора башласа, ялтыраса, начармы әллә?..

Кайсы гына мәгълүмат чарасына (интернет, телевидение, радио, газеталар) мөрәҗәгать итмә, һәммәсендә нидер тәкъдим итәләр, өндиләр, чакыралар. Рекламадан хәтта урамда да котылып булмый. Ул баннерларда, транспорт чараларында, кибет тәрәзәләрендә, хәтта фонарь баганалары белән асфальтта да – безнең зур булмаган шәһәрдә, тротуарлар кардан ачылуга, аяк астына һәр йөз метр саен такси номерларын язу гадәткә керде. Почта тартмасын ачсаң, анда да кырыкмаса кырык төрле буклет – нушкитмәле ташламалар, акцияләр, тагын әллә нәрсәләр.

Реклама шул дәрәҗәдә әрсез: ул сиңа һәр үтүктән, һәр ярыктан ябырылырга, башына ишелергә тора, ишелә. Аны шул ук телевизорда көненә җитмеш җиде тапкыр кабатлыйлар, сиңа монархы кирәкмәгән өч тиенлек әйберне шул дәрәҗәдә алыштыргысыз итәләр, минутында кибеткә торып йөгерүдән, ихтимал, бөтен кеше дә тыелып та кала алмыйдыр. Мантыйк күп очракта шундый: ул әйберне әле алмагансың икән – син дөньядан артта калган бер мескен. Әнә кара: миллионнар белгән артист ансыз хәзер гел яши алмый.

Сәүдәгәрләр рекламага миллиардлар тота. Чөнки түгелгән сумманың бише белән әйләнеп кайтасын белә. Кайтмый ин, халыкның олы өлеше реклама аша алар кармагында ич. Сәүдә, хезмәт күрсәтү сферасы өчен реклама – чыннан да, куалаучы. Бизнес – шуның өчен дә бизнес: аңа реализация, ягъни сатылган товар күләменең артып торуы, ким дигәндә кимемәве кирәк. Хет суган кабыгы сат, теләсә нинди алымнар, юллар кулланылсын – ул сатылып торсын. Шул ук язык-тәлек сатучыны, аны рекламалаучы, хәтта җитештерүчене дә гади кешенең мәнфәгатьләре, аның сәламәтлеге артык борчымый. Товарның, кешене җәлеп итү өчен, матур, ялтыравыклы төргәктә булуы мәсләхәт, саклану срогы зур булу зарур (консервант җәллау юк). Продукт начар сатылса ясса срогы чыгып, бозылып, чүплеккә атылса, барысы да, шул исәптән рекламачы да оттыра. Язуларынча, реклама әвәләүчеләр психологиядәге иң яңа ачыш-казанышларны куллана икән. Бүгенге реклама кешенең акылына түгел, аның хисләренә мөрәҗәгать итә. «Син бит тегендимондый гына түгел, син гаярь, син кабатланмас! Тагын да уңышлы һәм бай булыр өчен сиңа, фәлән алып баручы кебек, пепси эчеп йөрү фарыз! Ал син аны!» Купләр ала. Алар рекламаның әчемлектәге шикәрнең чамасыз икәнен, анда теш эмален эштән чыгаручы глюконат барлыгын ялгыш та әйтмәячәген исәпләми. «Акча түлә дә ал, күбенгәнче эч, ник шунда бөтенләй тешсез калмыйсың». Реклама әченә яшерелгән мондый җөмләне бик азлар гына ишетергә сәләтле. Менә шундыйрак хәлләрдән соң рекламаның гади сатып алучыга файдасы турында сөйләмәскә дә буладыр. Аның дөньяны яхшырак, кешене бәхетлерәк, сәламәтрәк итмәве тәгаен…

Реклама французчадан тәрҗемәдә нәрсәнедер кычкырып әйтүне аңлата, диләр. Элек базарларда товар исемен әйтеп кычкыру, сатып алучыны чакыру гадәте булганлыгы билгеле. Бүген реклама – теләсә кайсы илдә тулы бер индустрия генә түгел, кулланучының аңы белән идарә итеп торган җәйләнган-майланган шома механизм, инструмент. Анда әхлак юк, һәм була да алмый. Чөнки рекламаның максаты – адәми затны гомумкешелек кыйммәтләреннән аралап тору, аны куллану культының тотыгы иту. Рухи кыйммәтләрне читкә этәреп, бәндәне матди әйберләр артыннан чаптыру. Реклама хәтта кү бәхет төшенчәсен, аның асылын үзгәртә. Ул кешене аны урап алган һәм алачак төрледән-төрле уенчыклар, кирәге шуның кадәр генә булган җиһазлар аша «бәхетле» итмәкче. Реклама – капитализм продукты. Капитализмның үзе кебек үк ул намуслы да, гадел дә була алмый.

Шул ук телевизорны «зомбитартма» дип атаганда, без күпчелек сәясәтне күздә тотабыз. Ә бит реклама ягыннан караганда да аны шул сүз белән атау дөрес. Реклама кешенең әчке аңына – подсознаниегә кереп утырырга, шуннан бәндә белән идарә итәргә тырыша. Ул шуңа ирештеме, беттең: син – зомби. Син – туймас тамак – рекламаланган теләсә нинди әйберне үзеңнеке итәргә тырышучы. Реклама агентлыкларының тук тормышына караганда, җәмгыятебез хәйран зомбилашкан. «Яхшы реклама – матур упаковкага төрелгән ялган», – диләр. Шулай икәнен, рекламачыларның гыйффәтсез кызга кияү эзләүчеләр сыйфатында торуын чамаласак та, кубебез аның йогынтысында кала…

Реклама котыртучыдан мәгълүмат бирүчегә әверелергә тиеш. Бары шул чакта гына аның гонаһлары бетәчәк. Кирәк булганда кеше үзе сатып ала, почта тартмасына ташланылмый торган реклама газеталары бар. Телевидениедә да, канал саен нәрсәнедер мактый-мактый, сыйфатын күпертә-күпертә бәндәне азындыргачны, йөз каналның бер-икесе махсус, бары реклама өчен генә тотылса, дөресрәк булмас идеме? Булыр иде, тик без, алда язылганча, капитализмда яшибез. Һәр каналның, һәр сайтның җиңел генә акча эшлисе килә. Акчадан ис килми ич.

КАЗАН СУЫ ДУСЛАШТЫРА

Спорт кына түгел бу

17 ил һәм 1,3 меңнән артык спортчы. Казанда «Дуслык Уеннары» башланды. Әлеге спорт ярышларының беренче этабы «Дөнья» дип атала һәм 3 августка кадәр Татарстан башкаласында йөзүчеләр, суга сикерүчеләр, синхрон йөзүчеләр чыгыш ясаячак. Тагын ике этап ноябрь һәм декабрьгә билгеләнгән.

Мәгълүм сәбәпләр аркасында спорт дөньясына сәяси каршылык тагын да ныграк үтеп кергәч, халыкара оешмалар Россиядә ярышлар уздырудан баш тартты. Әйтик, Казанда йөзү буенча ике дөнья чемпионатына узарга тиеш иде. Спортчыларга исә тик утырырга ярамый. Шулай итеп, Татарстан башкаласында яңа ярышлар уйлап таптылар. 22 июльдә Казанда «Дуслык Уеннары»ның беренче этабы башланды.

Ярышны ачу тантанасында илнең спорт министры Олег Матыцин да катнашты. «Спорт – иң нык берләштерүче көчләрнең берсе. Ә аның дуслык, бер-береңә терәк булу һәм кагыйдәләр буенча уйнау кебек шартлары бөтен кешегә дә кагыла. Ярышларда танылган спортчыларның чыгыш ясавы яшьләргә дә, тамашачыга да кызык булачак», – диде ул һәм әлеге бәйрәмне булдыруга ярдәм иткән өчен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка, Казан шәһәре җитәкчелегенә, федерация башлыкларына һәм оештыручыларга рәхмәт әйтте.

Казан мэры Илсур Метшин Татарстан башкаласының зур спорт чаралары сагынуын әйтте. Россиянең йөзү федерациясе башлыгы Владимир Сальников спортчыларның Казанны һич өчен туган шәһәрләре кебек яратуларын җиткерде. Ә Россия спортчыларыннан тыш, ярышларда Алжир, Әрмәнстан, Белоруссия, Венесуэла, Вьетнам, Сербия, Казахстан, Сүрия, Судан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Эквадор, Көньяк Африка Республикасы, Донецк һәм Луганск халык республикалары спортчылары да чыгыш ясый. Араларында Олимпия һәм дөнья чемпионнары, мондый дәрәҗәгә киләчәктә иң булачак яшь спортчылар да бар. Ил җыелма командасы составына Татарстаннан 48 спортчы кергән. Алар барлыгы 376 комплект медаль өчен көрәшәчәк.

Ноябрь һәм декабрьдә «Дуслык Уеннары»ның тагын ике этабы узачак. 9–26 ноябрьдә буласы «Спорт» этабында суга сикерүчеләр Татарстан Президенты Кубогын оту өчен көч сынашачак һәм йөзү буенча халыкара ярышлар булачак. 15–26 декабрьдә буласы этап «Легендалар» дип атала. Анысында йөзүчеләр, суга сикерүчеләр һәм синхрон йөзүчеләр Владимир Сальников, Дмитрий Саутин һәм Светлана Ромашина кубоклары өчен ярышачак.

Уйларга вакыт

Үзебезнеке булсын. КФУ галимнәре уйлап тапкан яңалыклар чит илләргә бәйлелектән котылу белән бергә, нәтиҗәлерәк эшләргә дә мөмкинлек бирә. Әйтик, яңа алымнар куллану экологиягә зыян күләмен киметәчәк. Федераль университет карамагындагы Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк (НЦМУ) белән таныштырганда, журналистларга әнә шул хакта сөйләделәр.

«Планетаның сыек углеводород запасларын нәтиҗәле үзләштерү» Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни үзәк Россия Хөкүмәте карары буенча «Фән» илкүләм проектын тормышка ашыру кысасында булдырылган. Бирегә ил икътисадын арзанлы һәм экологик нефть белән тәэмин итүгә юнәлтелгән тикшеренүләр алып барыла һәм эшләнмәләр уйлап табыла. КФУдан тыш, Россиянең нефть-газ ятмаларын өйрәнү һәм нефть чыгаруның яңа технологияләрен булдыру өлкәсендә алдынгы саналган тагын өч университетның фәнни үзәкләр эшләп килә.

Нефть чыгаруның нәтиҗәлелеген арттырудан тыш, фәнни үзәк углеводородларны эзләүнең заманча ысулларын булдыру, нефть һәм газ ятмаларын эшкәртү, авыр нефтьне чыгару мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

– Безнең эшләнмәләр Россиянең алдынгы нефть компанияләрендә, Татарстанның кече һәм зур предприятиеләрендә кулланыла. Төрле нефть компанияләре белән эшлибез. Төп партнерыбыз – «Татнефть». Безнең эшләнмәләрне Көньяк Америкада, Кубада, Якын Көнчыгышта, Кытайда куллану тәҗрибәсе дә бар. Шактый кирәкле, димәк. Әлеге продуктлар һәм технологияләр нефть-газ секторы өчен бик мөһим, – ди фәнни үзәкнең нефть бирүчәнлеген арттыру алымнары юнәлеше җитәкчесе Михаил Варфоломеев.



Шулай итеп, Россиягә карата санкцияләр кертеп, илне заманча технологияләрдән аерырга омтылу әлеге үзәкнең әһәмиятен тагын да арттыра. Моңа кадәр чит илләрдән сатып алынган химикатлар һәм башка матдәләрне НЦМУда ясарга тырышалар.

Фәнни үзәк белгечләре әлеге проектка яшьләрне дә җәлеп итүне мөһим дип саный. Шул максаттан КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институтында өстәмә белем бирү, сыйфат менеджменты һәм маркетинг үзәге оештырылган. Бирегә Россия һәм чит ил белгечләрен алдынгы нефть-газ технологияләренә өйрәтәләр.

Сыек углеводородларны үзләштерү буенча дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәкнең лабораторияләрендә нефть чыгару шартларын җиңеләйтергә мөмкинлек бирүче җайланмалар эшлиләр. Үзәкнең фәнни җитәкчесе, КФУның нефть-газ технологияләре, табигатьтән файдалану һәм җир турындагы фәннәр юнәлешләре буенча проректоры Данис Нургалиев нефть чыгару һәм эшкәртү, нефть химиясе өлкәсендәге заманча эшләнмәләр турында сөйләде.

– Россиядә нефть запаслары гаять күп. Әмма нефтьнең күп өлеше зур авырлык белән табыла, аны чыгару кыенлаша. Шуның өчен без төрле технологияләр кулланабыз. Нефтьне чыгару өчен күбрәк химик ысуллар куллануга игътибар бирәбез. Проектларны Россия компанияләре өчен генә түгел, чит ил компанияләре өчен дә эшлибез. Алар бик кызыксына, – ди ул.

Данис Нургалиев әйтүенчә, ике ел элек әчендә университет галимнәре нефтьне чыгару һәм җитештерү буенча төрле инновацион җиһазлар булдырган. Шуларның берсе – катализатор. «Катализаторлар нефть чыгару коэффициентын арттырырга мөмкинлек бирә. Бу уникаль җиһазлар Көнбатыш аналогларын да алыштырырга сәләтле», – ди галим.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе територияль фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре: финанс хисаплары идарәсенең финанслар белән тәэмин итү һәм хисап булеге башлыгы урынбасары **Баркова** Ольга Витальевнага; финанс хисаплары идарәсе башлыгы **Газизова** Наталия Григорьевнага; планлаштыру һәм икътисадый анализ идарәсе башлыгы **Галкина** Гүзәл Миңнехан кызына; планлаштыру һәм икътисадый анализ идарәсенең мәҗбүри медицина иминиятләштерү программаларын формалаштыру һәм мониторинглау булеге башлыгы **Гыйсмәтуллина** Римма Тәлгат кызына, мәҗбүри медицина иминиятләштерү программалары белән тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү булеге башлыгы **Дёмин** Алексей Анатольевичка; директор урынбасары **Зәкәриева** Гүзәлия Камил кызына, мәгълүматлаштыру идарәсе башлыгы урынбасары **Ибраһимов** Фәнил Илһам улына; мәҗбүри медицина иминиятләштерүен үстерү идарәсе башлыгы **Мәгъсүмова** Дилия Рәвгать кызына; директор урынбасары **Мөхәммәтҗанова** Марина Владимировнага; медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тотуны оештыру идарәсенең медицина экспертизалары булеге башлыгы урынбасары **Нураева** Резеда Вакыйф кызына; медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тотуны оештыру идарәсенең медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тоту булеге башлыгы **Полякова** Ольга Петровнага; директор урынбасары **Романов** Дмитрий Валентиновичка; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Хузангай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең чуаш теле һәм әдәбияты укытучысы **Чернова** Наталья Николаевнага; Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «2 номерлы лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Киселева** Ирина Борисовнага; Чаллы шәһәренең «77 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Корелова** Светлана Владимировнага; Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Нәгыймова** Светлана Владимировнага; хезмәт ветераны **Тәхаутдинова** Гөлсәрия Сарыйм кызына; Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары, география укытучысы **Хәбибуллина** Рәйсә Харис кызына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты геофизика һәм геомәгълүмат технологияләре кафедрасының 1 категорияле инженеры **Шәрәфетдинова** Юлия Юрьевнага; Казан шәһәре Совет районының «93 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Шлямина** Ирина Борисовнага **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасының башлангыч ветеран оешмалары белән эшләү буенча даими комиссиясе рәисе урынбасары **Ахмаев** Тагирян Зиннур улы, «Түбән Кама медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Нуретдинов** Ринат Кыям улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе **Нуриев** Фәнис Галиәхмәт улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

ГҮЗӘЛ МАКАРОВА:

«КЕШЕ ЕЛЫНА 500 КИЛОГРАММ ЧҮП ТАШЛЫЙ»

Яшәеш

Экоактивист Гүзәл Макарова, табигатьне саклау чүптән башлана, ди. Әйтеп кенә калмый, шул юнәлештә актив эшли дә. Әйтик, көнкүреш калдыкларын төрләргә аера ул. Шулай иткәндә күп дә чүп ташларга кирәкми икән. Гүзәл Макарова чүп ташларга моннан 6 ай элек чыккан.

Макаровлар гаиләсе һәр кешене үзләренә ияреаргә өнди. Гүзәл исә бу хакта моннан ун еллап элек уйлана башлаган.

– 2011 елларда калдыкларсыз яшәү хакында уйлана башладым. Тик нигәдер вакытны сузып килдем. 2016 елда пластик 100 елдан соң гына таркала дигән язу күреп алдым. Әнә шул сүзләр мине уйландырды да, үзгәртте дә. Әгәр хәзер кулланган чүпләремне җиргә ташлыйм икән, мин дөньядан киткәндә дә алар таркалмаган була. Шуннан соң, беренче эш итеп, чүпләрне аерып җыя башладым, – ди ул.

Гүзәл соктан бушаган кәгазь тартмаларны су белән чайкап, киптереп, җыеп бара башлый. Аларны эшкәртүгә тапшыра икән. Пластик шешәләр дә аерым җыела. Аларын да эшкәртүгә тапшыра. Ярма, чәй, кәнфитләрдән бушаган тартмалар да шунда китә. Чүпләрне аерып җыя башлагач, шакката ул. Өе калдык белән тула башлый.

– Мин исәпләп чыгардым: бер кеше елына ким дигәндә 400–500 килограмм чүп ташлый. Чүпне икенчел эшкәртүгә бирү дә җиңел эш түгел. Аның өчен биргән акча юл чыгымын да капламый. Мин барысын да уйладым да калдыкларны киметү җаен эзли башладым. Кайбер төр әйберләрне кулланмый башладым. Нәрсәдер сатып алыр алдыннан кат-кат уйланам. «Миңа кирәкме бу?» – дим. Шкафта тик ята торган чүп-чарга әйләнмәсме дип тә уйлыйм. Киемне дә өстә-өстенә җыймыйм. Баланмы подгузниксыз гына үстердем. Гигиена әйберләренең дә киҗе-мамыктан ясалганын гына кулланам. Агачтан ясалган мамыклы таякчыклар, күп тапкыр кулланылышлы киҗемамык дисклар. Аларны кер машинасында да юарга була. Бамбук савытка салынган минераль дезодорант кулланам.

Аны тыңлау кызык. Әйтүенчә, шәхси йортта яшәү тормышны җиңеләйтә. Ризыкны күп итеп пешерми, артып кала икән, җиргә күмә. Череп, табигый ашлама була, ди. Бер тапкыр куллана торган пластик савытларны да тапмассың аларда. Хәтта бахилның да чүпрәктән тегкән кияләр.

– Чүпрәк сумкага күчкәч, иң кыены иремә булды. Мин моны тотып йөрмим, диде. Җаен таптык – ул кибеткә рюкзак белән йөри башлады. Безнең өйдә бер генә полиэтилен пакет бар. Бер тапкыр ипидән бушаган иде. Әле дә шуны саклап тотабыз. Ул гел безнең белән. Бик кирәк булганда, кулланабыз. Искергәч, аны эшкәртүгә бирә була. Экологик пакетларның зарарлы түгел дип сөйләгән булалар. Яңасе, үзе чери. Юк шул. Алар башта микропластикка әйләнә, аннары шактый озак таркала, – ди ул.

Гүзәл Макарова чүпне аерып җыя белмәвебезгә борчыла.

– Җыйган очракта да, хәтта аерып салганын сатыйга салганда да, машина килеп, бөтенесен бергә алып китә. Чит илләрдә бөтенләй башкача бит. Алардан без кимме-ни? – ди Гүзәл. – Германиядә калдыкларны юеш, исле, иссезгә бүләләр. Бездә исә чүпнең кайсын кая ташларга икәнне аңлаткан билгеләр дә юк. Гап-гади эш әле дә эшләнмәгән. Чүпне аерырга өйрәтүнең бер юлы бар – калдыкларны чыгарган өчен түләүне үзгәртү.

Гүзәл Макарованың шәхси архивыннан

Гүзәл, кем күпме чүп ташлый, шуның өчен генә акча түли башласа, күп кеше калдыкларны эшкәртергә бирү ягын карар яки куллануны киметер иде, дип уйлый. Болай эшләгәндә, күпме акча янга калыр иде, ди ул. Чүпне төрләргә аерасы килмәгән кешеләргә, төрле төсләрдәге махсус пакет алдырып, шунда җыйдырырга кирәк дигән фикер дә әйтә.

– Без чүпләрне өч төргә аерып чыгара алмыйбыз. Япониядә чүпне 40 төргә аералар. Кемнең нәрсә ташлавын камерадан карап була. Буталасың икән, яныңа килеп тә җитәләр һәм административ җаваплылыкка тарталар. Бездә кеше бер елга исәпләнгән калдык нормасын апрель аенда ук тутыра. Калган айларда кулланган чүп-чар табигатькә зур зыян китерә, – ди Гүзәл. – Кешенең чүп турында уйлар вакыты юк шул аның. Нигәдер авырсынабыз, иренәбезме шунда?! Ә бит киләчәккә кайгырту үзебездән тора. Балаларыбыз ни сулар да нинди шартларда яшәр соң? Полиэтилен капчыкны чүпрәккә генә алыштырсак та, Җир-анабыз рәхмәтен әйтеп бетерә алмас иде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«МИЛЛӘТЕБЕЗ ҮЗ ЙӨЗЕНӘ ТАП ТӨШЕРМӘДЕ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ МИНТИМЕР ШӘРИП УЛЫ ШӘЙМИЕВНЕҢ БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЪЕЗДЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЫННАН

Юл башы

Кадерле кунаклар, ватандашлар – татар халкының газиз уллары һәм кызлары!

Без бирегә, үзебезнең тарихи Ватаныбызга, үз дәүләтебез Татарстанга төрле иләрдән җыелдык. Без – бүген Җир шарында көн күрүче татарларны берләштерүче, барлык татарлар исеменнән рәсми сүз әйтә алучы олы һәм вәкаләтле мәҗлес. Ата-бабаларыбыздан калган, тарихның иң кырыс җилләрендә дә тузмаган-таушалмаган гадәт буенча сезгә: «Исән-имин килеп җиттегезме? Өстәлләребез түгәрәк, мәҗлесебез мөбарәк булсын!» – дип әйтергә рөхсәт итегез.

Ә тарих җиле, язмыш җиле татарларны континентлар, илләр буйлап сипкән дә сипкән: ата-аналар – улларыннан-кызларыннан, туганнар – бер-берсеннән, дуслар дусларыннан аерылган. Без бүгенгә кадәр:
«Сибелә чәчәк җилләр искәндә,
Өзелә үзәк исемә төшкәндә», –
дип бер-беребезне сагынышып, сулыгып-сулыгып җырлыйбыз.

Бүген Казаныбызга – бөтен татар халкының төп йорты булган Татарстан башкаласына – Башкортстанда, Үзбәкстан, Казахстан, Төмән өлкәсе, Урал, Идел буе, Мәскәү һәм Санкт-Петербургта, Себердә, күрше республикаларда һәм өлкәләрдә, Бердәмлек дәүләтләрендә яшәүче ватандашларыбыз килде. Татарлар көн итмәгән республиканы яки өлкәне табу кыен һәм алар барысы да дәүләтебезнең башкаласы Казанга үзләренең вәкилләрен җибәрделәр.

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез хакында аерым әйтергә телим. Озак еллар буе без алар белән әйбәтләп аралаша алмадык. Монда безнең гаеп юк. Тарих, ачы язмыш шулайрак булды. Татарлар Татарстанга килеп, мәдәни, фәнни һәм экономик элемтәләр урнаштырдылар, Сабантуйларда булдылар, үзләренең туган-тумачаларын, ата-бабаларының каберләрен эзләп таптылар, яңа дуслар булдырдылар. Ә безнең гражданнар туганнары, дуслары, коллегалары янына башка илләргә бардылар. Без моңа чын күңелдән шатланабыз, һәм, ниһаять, безгә АКШтан, Төркия, Финляндия, Германия, Польша, Япония, Австралия, Кытай, Швеция, Норвегия, Румыниядән абруйлы делегацияләр килгән күркәм көн дә менә җитте. Татарстан Республикасы аларның барысына да: «Уртак Ватаныбызга рәхим итегез, кардәшләр, милләттәшләр!» – дия ала. Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар Татарстанның чын патриотлары булдылар, һәм моның өчен мин аларның барысына да, сезнең барыгызга да халкыбыз исеменнән олы рәхмәтемне белдерәм!

Минем Указ нигезендә чакырылган бу конгресс татарлар яши торган төбәкләрдә халыклар арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуга юнәлдерелгән фактор булып хезмәт итәр дип өметләнәм һәм моңа иманым камил. Безнең ниятләребез ак, алар беркемнең мәнфәгатенә дә аяк чалмый һәм без бу хакта бүген дөнья каршында ачыктан-ачык әйтәбез.

Халкыбыз өлешенә михнәтле язмыш туры килде. Анда горурланып сөйләрлек сәхифәләр булган кебек, үтә авыр түбәнсетү еллары да булды… Бүген узганнарны искә төшереп яраларга тоз саласы да килми, ләкин дәреслекләрдә, фәнни һәм матур әдәбиятта тарихыбызның гаять дәрәҗәдә бозып күрсәтелүе йөрәкләребезне әрнетә. Татарлар турында ялган-уйдырмалар бихисап күп җыелды шул. Кайбер халыкларда татар сүзе үзе үк курку һәм ышанмаучылык тудырды. Татар халкы мондый гаделсезлеккә лаек түгел. Ул гомер-гомергә тыныч хезмәт белән шөгыльләнде, икмәк үстерде, сәүдә итте, китаплар бастырып таратты, татар балаларына гына түгел, Шәрекъ халыкларының күпчелек ул-кызларына мәгърифәт нуры чәчте, укытты, сугышырга туры килгәндә дә, фәкать үзенең газиз җирен генә яклады. Без дөнья җәмәгатьчелеге аңында «явыз» татарлар, татар-монгол изүе хакында уйдырмаларны юк итәргә, безнең халкыбызга һәм республикабызга карата ялган карашларны бетерергә тиешбез. Бу – безнең бурыч.

> Татарлар турында нәрсә генә сөйләсәләр дә, милләтебез бернинди гамәле белән дә үз йөзенә тап төшермәде. Безнең оялыр урыныбыз юк. Халыкның иң күркәм сыйфатлары буыннан-буынга күчеп барды, алар камилләштеләр, кайберләре вакытлар узу белән төшеп калдылар, ә кайберләре алдагы буыннарга тапшырылды.

Менә шул сыйфатларның берсенә – аң-белемгә омтылышка – аерым тукталасым килә. Күп кенә галимнәр татарларның бу асыл сыйфатын гаҗәпсенеп, басым ясап күрсәтәләр. Татарларның көнкүрешен һәм холык-фигылен озак еллар өйрәнгән Казан университеты профессоры Карл Фукс сокланып: «Читтән килгән һәр кешегә, гомумән алганда, Казан татарларының башкалар белән, хәтта Европа халыклары белән чагыштырганда да, белемлерәк булуы, һичшиксез, сәер тоелырга мөмкин. Укый һәм яза белмәгән татарны якташлары кешегә санамыйлар һәм ул, гражданин буларак, башкалар арасында абруйсыз», – дип язып калдыра. Хәзерге шартларда мондый сыйфат гаять мөһим, чөнки, ахыр чиктә, нәкъ менә белемле булу безне дөньяның алдынгы милләтләре рәтенә бастырырга мөмкин.

(…) 1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан ителде. Ул Татарстанны суверен дәүләт итеп билгеләде, үз территориясендә Республика законнарының өстенлеген таныды, җирне, җир асты байлыкларын, табигать хәзинәләрен һәм башка ресурсларны республиканың күпмилләтле халкы мөлкәте итеп беркетте. Сәяси-хокукый планда бу – хокукый дәүләт нормаларына туры килә торган эш. Ул татар һәм рус халкының да, Татарстанда яшәүче башка милләтләрнең дә мәнфәгатьләренә җавап бирә. Декларация республикада милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга хезмәт итә һәм мин аның бөтен татар милләтенең демократик омтылышларына туры килүенә чын күңелдән ышанам. Шуңа күрә дә бу көн бездә, хаклы рәвештә, Республика көне, олы бәйрәм көне итеп билгеләнде.

1992 елның 21 мартында уздырылган референдум Татарстанны Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән үзенең мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә билгеләүче суверен дәүләт дип игълан итүче сәяси курсны раслады. Шик-шөбһәләр алып ташланды. Без үз юлыбызны сайладык.

(…) Татарстанда безнең республиканы әүвәлгечә Россия составындагы гап-гади бер автономия сыйфатында сакларга тырышучылар да, Россия Федерациясе белән элемтәләрне тулысынча өзәргә чакыручы сәяси көчләр дә бар әле. Карашларның тегесе дә, бусы да кабул ителерлек түгел. Без сәясәтебезнең һәм экономикабызның нигезен тәшкил итүче үз суверенлыгыбызны корбан итә дә һәм шул ук вакытта Россия белән озак еллар яшәп килгән экономик һәм мәдәни элемтәләрне өзә дә алмыйбыз. Без үзара мөнәсәбәтләрдә иң кулай һәм җайлы юлларны табарга тиешбез. Экономикабыз да, геополитик хәлебез дә, Россиядә миллионлаган милләттәшләребезнең яшәве дә моны эшебездә исәпкә алырга мәҗбүр итә. Без тулаем татар халкы турында уйларга бурычлы. Мин Татарстан бөтен татар диаспорасын берләштерүче булырга һәм Россиянең милли сәясәтенә җитәрлек дәрәҗәдә йогынты ясарга тиеш дип исәплим.

(…) Теләсә кайсы милләт турында чыгарылган нефть тонналары, үстерелгән ашлык яки башка продукциягә карап кына түгел, ә аның мәдәниятенә, фән һәм техника өлкәсендәге казанышларына, атаклы шәхесләренә, язучыларына, шагыйрьләренә, галимнәренә карап фикер йөртәләр. Бу җәһәттән, мин әйтер идем, без – бәхетле милләт.

(…) Безнең мәдәниятебез, чыннан да, бик бай. Тик аның хакында, күренекле шәхесләребез хакында, башка халыклар димим инде, татарлар үзләре дә аз беләләр. Аларның һәркайсын искә төшерү һәм барысына да тиешле рәхмәтне әйтер вакыт җитте. Бүген кайсы сәяси эшлекле реакционер, ә кайсысы революционер, кайсы язучыны бастырырга һәм дәреслекләргә кертергә, ә кайсысын онытырга дип баш ватарга кирәкми. Аларның һәммәсе дә тормышыбызда үзенең урынын алды. Алар барысы да – озак көткән азатлык көнен якынайтырга омтылган кешеләр. Алар тормыш юлын лаеклы уздылар.

(…) Төрле республикаларда һәм өлкәләрдә яшәүче язучылар бер-берсе белән аралаша алмадылар. Без үзебезнең Үзбәкстанда, Казахстанда, Петербургта һәм башка төбәкләрдә иҗат итүче рәссамнарыбызны фәкать ишетеп кенә белә идек. Күп кенә татар архитекторлары бөтен ил буйлап шәһәрләр төзеделәр, кинематографистлар барлык республикаларда фильмнар төшерделәр, ләкин үзләренең белемнәрен һәм хезмәтләрен Татарстанга бирүдән мәхрүм иделәр. Хәзерге көннән башлап татар язучылары, композиторлары, рәссамнары, архитекторлары, кинематографистлары үзләрен, кайда гына яшәсәләр дә, безнең иҗат берлекләренең дә уртак гаиләсендә дип хис итсеннәр иде.

(…) XIX йөз ахыры – XX йөз башы татарлар өчен мәдәниятнең бик тиз үскән чоры булды. XXI гасыр чигендә торганда да татар милләтенең һәм аның мәдәниятенең үсешендә яңа күтәрелеш булыр дип ышанасы килә. Минем тарихи гаделлекнең тантана итүенә иманым камил.

19 июнь, 1992 ел

ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

БЕР МӘЙДАНДА

«Татар-информ»

1992 елның июнендә Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә Бөтендөнья татар конгрессы оеша һәм аның беренче съезды уза. Өч дистә елдан соң конгрессның татар дөньясында тоткан урыны, максатлары үзгәргәнме? Бу турыда Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Гаяз улы ШӘЙХРАЗЫЕВ белән сөйләшәбез.

:: Васил Гаязович, Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең төп максаты нидән гыйбарәт?

– Бөтендөнья татар конгрессы – татар иҗтимагый берләшмәләре берлеге – Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә төзелгән 450дән артык милли-мәдәни оешманы берләштерә. Безнең максат – халкыбызны берләштерү, тарихыбыз, телебез, динебез, мәдәниятебез, әдәбиятыбыз, милли мирасыбызны саклау һәм баету. Менә 30 ел дәвамында Бөтендөнья татар конгрессы шушы юнәлештән тайпылмыйча эш итә. Дөньяга сибелгән халкыбызны бер мәйданга туплау, алар белән эзлекле эш алып баруыбыз ил күләмендә дә игътибар үзәгендә. Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров Бөтендөнья татар конгрессының чит илләрдәге Россия ватандашларын алга этәрү һәм аларның мәнфәгатьләрен яклау эшенә зур өлеш кертүен ассызыклады. «Бөтендөнья татар конгрессы чит илләрдә Россия Федерациясенең барлык халыкларының мәнфәгатьләрен алга этәрү буенча «йомшак көч»нең мөһим инструментларыннан берсе булып тора. Казан чит илләрдә ватандашлар эшләре буенча хөкүмәт комиссиясенең бик актив катнашучысы буларак тәкъдим ителде, шулай ук Татарстаннан килгән дусларыбыз да Россия Федерациясе субъектлары башлыклары советында актив катнашалар, ул Россия Тышкы эшләр министрлыгы каршында эшли», – дип билгеләп үтте. Димәк, конгресс тарафыннан башкарылган эшләр эзсез үтми.

:: Бөтендөнья татар конгрессы нинди этапларны кичерде? Һәм хәзер ул нинди этапта?

– Гомумән алганда, татар җәмәгатьчелеге белән эшчәнлек Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев инициативасы һәм ярдәмендә яңа халыкара берләшмәне формалаштыруга бәйле. Беренче этап – Бөтендөнья татар конгрессы структураларын формалаштыру, программа һәм устав документларын эшләү һәм теркәү берлек эшчәнлегенең беренче биш – ун елына туры килә. Бу чорда илдә сәяси вазгыять, икътисад һәм финанслар катлаулы хәлдә иде. Нәкъ менә шул вакытта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хакимият органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү турында килешү төзелде. Татарстанның федераль үзәк һәм төбәкләр белән хезмәттәшлеге мәсьәләсендә татар факторы роль уйнады.

Икенче этап – ил икътисадында һәм социаль үсешендә яңа цикл башлану, базар мөнәсәбәтләрен ныгыту. Ул Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның Татарстан җитәкчелегендәге эшчәнлегенә бәйле. Президент татар җәмәгатьчелегенә һәрвакыт ярдәм итә, безнең проектларны тормышка ашыруга хәер-фатихасын бирә. Татарстан һәм татар дөньясы бер-берсенә таяна, ил һәм халык файдасына конструктив хезмәттәшлек итә. Бу чорда (2005–2010 еллардан башлап) төбәк татар үзәкләренең һәм иҗтимагый берләшмәләрнең, ассоциацияләрнең (яшьләр, хатын-кыз, эшмәкәрлек, дин әһелләренең) гамәли эшчәнлеге җайга салынды.

Хәзерге этап төбәкара элемтәләрне үстерүгә һәм татарлар яшәгән төбәкләрнең хакимият органнары белән хезмәттәшлекне үстерүгә багышланган. Бу чорда 1000 һәм аннан да күбрәк кеше катнашында зур масштаблы чаралар, форумнар, россиялеләрне патриотик рухта тәрбияләүгә юнәлдерелгән халыкара конкурслар үткәрелә. Эпидемияләр, кризислы төбәкләрдә катлаулы халыкара вакыйгалар татар дөньясы өчен дә сынау булып тора.

> Татарларның милли җәмгыятьләре илнең һәм дөньяның төрле төбәкләрендә урнашкан. Шуңа күрә Бөтендөнья татар конгрессы хәзерге катлаулы шартларда позитив булырга омтыла, чөнки без сәламәт, патриотик көчләр, конструктив һәм гуманлы бурычлар тирәсендә берләшергә тиешбез.

:: Өч дистә ел эчендә Бөтендөнья татар конгрессында иң төп казанышлар нинди булды?

– Әйткәнемчә, Бөтендөнья татар конгрессы безнең барлык милләттәшләребезне берләштерү үзәге һәм таянычы булып тора. Бу еллар эчендә без бөтен дөнья буйлап татарларның этномәдәни үзенчәлеген, милли үзенчәлеген саклау утрауларын булдыра алдык. Күпьеллык системалы эшчәнлекнең иң мөһим нәтиҗәләреннән берсе – «Татарлар: гамәл стратегиясе» документын булдыру һәм кабул итү. Аның нигезендә гамәлдәге стратегияне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре эшләнде. Йөзләгән милли оешма һәм мәдәни үзәкләр гуманитар процессларга этномәдәни йогынты ясау коралы алды.

:: Моннан 5 ел элек барлыкка килгән Милли Шура нинди роль уйный? Бу структура үз эшчәнлеген акладымы икән?

– Милли Шура булдыру татар милли үсешенең магистраль юлларын билгели һәм координацияли. Алар нигезендә татар җәмгыятьләре һәм оешмалары гуманитар юнәлешләр буенча гамәли эш алып бара. Ә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, көчләрне мобилизацияләүне, кадрлар һәм оештыру мөмкинлекләрен һәм ресурсларын координацияләүне тәэмин итә.

:: Васил Гаязович, Милли Шура рәисе булып сайлангач узган 5 ел сезнең тормышны, яшәешне, дөньяга карашны үзгәрттеме?

– Бик нык үзгәртте дип әйтә алмыйм. Беренчедән, мин бу эшкә татар кешесе буларак та, җитәкче буларак та әзер идем. Икенчедән, Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, хезмәткәрләр белән бер команда булып эшли башлагач, эшнең асылына төшенергә авыр булмады. Җай гына татар дөньясы агымына кереп киттем.

Милли Шура сайлангач, Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеге хөкүмәт дәрәҗәсенә күтәрелде. Россиянең башка өлкәләрендә, республикаларында милләттәшләребезне борчыган мәсьәләләрнең шактые уңай хәл ителде. Татар шәхесләренә һәйкәлләр куелды, истәлек такталары ачылды, музейлар төзелде, татар оешмаларының офислары барлыкка килде, милли үзәкләр, парклар төзелде…

:: Шушы биш ел эчендә сезнең тарафтан кайсы төбәктә башкарылган эшне зуры, иң уңышлысы дип саныйсыз?

– Кайбер кешегә 1 сум бирәсең, ул сиңа гомер буе рәхмәт укый. Кемгәдер миллион бирсәң дә җитми яки ул аны оныта. Шуңа күрә минем үзем өчен дә һәм безнең команда өчен дә зур һәм кечкенә эшләр юк. Аннан, зур эшне ничек бәяләргә соң? Сумнар беләнме, квадрат метрлар беләнме? Һәр эш чын күңелдән башкарылырга, йөрәктән чыгарга һәм халкыбызга файдалы булырга тиеш.

Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык тарихында халкыбыз өчен шактый игелекле эшләр кылынган. Беренче җитәкчебез – тарих фәннәре докторы, академик Индус Таһиров 1992 елдан 2002 елга кадәр эшләп, татар оешмаларын берләштереп, бүгенге конгрессның нигезен һәм кирпечләрен сала. Аннан соң килгән җитәкче Ринат Закиров, шул фундаментка таянып, күп кенә проектларны тормышка ашырды. Мин килгәч, без шул проектларны дәвам итеп, баетып, регионнардагы милли оешма җитәкчеләребез һәм ул төбәкләрнең хакимиятләре белән берлектә эш алып бара башладык. Бу инде – татар эшләрен оештыру нигезенә хөкүмәт ягыннан турыдан-туры ярдәм алу. Һәр этапның үз вакыты, үз эше бар. Әйткәнемчә, мин тормышка ашырылган эшне азга да, күпкә дә бүлмим. Үткән көн, нинди генә булса да, бәхетле булырга тиеш. Татар кайда гына яшәсә дә, без, Казаннан килеп, аларга ярдәм итә, файда китерә алабыз икән, шушы ярдәмне файдаланып, халкыбызга уңайлык тудырабыз икән, безнең миссия үтәлгән дигән сүз.

Әңгәмәдәш – Гөлназ ШӘЙХИ

Татармын! Горурмын!

Илшат НУРИЕВ, Арча районы башлыгы:
– Татарлык һәркемнең күңелендә булырга тиеш ул. Мин еш кына шагыйрь Разил Вәлиевнең, телне саклау түгел, сөйләшү кирәк, дигән сүзләренә тукталам. Татар теле яшәсен дисәк, өйдә, туганнар белән гел үз телеңдә сөйләшергә кирәк. Мин кая барсам да, иң элек сүзне татарча башлыйм. Читтәге милләттәшләрне карагыз. Алар телне кадерләп саклый. Халкың белән сөйләшсәң генә телне үстереп була. Мин гел бер фикер әйтәм: мәктәптә бала башлангыч белемне татарча алырга тиеш. Олырак сыйныфларда физика, химия, биология керә башлагач, русча укысыннар. Бу гына телне какшатмый. Әгәр син аны беләсең икән, онытмыйсың. Районда телне саклар өчен күп эш башкарыла. Тукай ягы булуыбыз, телне кадерләп саклавыбыз белән горурланам.

Фирдүс ТЯМАЕВ,
Татарстанның атказанган артисты:
– Татар булуым белән бик горурланам. Мин бу хакта күкрәк киереп кычкырып сөйлим, җырлыйм. Шөкер, быел күп эшләнелде. Үзбәкстанга барып, андагы татарлар белән күрешеп, аларның күңелен рухландыру өчен җырлап кайттык. Мордовия өлкәсендә узган Бөтенроссия Сабан туенда катнаштык. Кайда да «Татарлар» җыры яңгырады. 4 көн рәттән Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездында катнашам. Мин – үз илемнең, телемнең патриоты. Башкаларга да шуны телим. Кайда гына чыгыш ясасам да, яшьләргә татар булуыннан оялмаска кушам. Киресенчә, мин – татар, дип күкрәк киереп йөрергә кирәк. Модага ияреп, вата-җимерә русча сөйләшү эшмени ул? Үз телен санлаган, данлаган милләтнең генә киләчәге бар.

Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА, яшь җырчы:
– Татар җырлары белән мәдәниятебезне Россиядә генә түгел, чит төбәкләргә дә таныту өстендә эшлибез. Башкалар да татар җырын тыңласын, дибез. Зур хыялым бар: татар халык җырларын җыеп, альбом чыгарасым килә. Интернеттан эзли башласаң, халык җырлары бик аз. Шушы хыялымны тормышка ашырырга иде. Үземнең татарча җырлавым, сөйләшүем өчен мин әтиемә рәхмәтле. Безгә гаиләбез белән Екатеринбург шәһәрендә яшәргә туры килде. Шул вакытта татарча сөйләшү кимеде. Әтиебез, телне саклар өчен, безне Казанга кайтарып җибәрде. Миңа калса, һәр гаилә үзенең туган теле турында үзе кайгыртырга тиеш. Мин телне саклауның башка юлын белмим дә. Бары тик гаилә генә ярдәм итә ала.

Финзия ГАЗИЗОВА, Австралиядә яшәүче татар:
– Язмыш кушуы буенча чит җирдә яшәсәм дә, мин Балтач кызы, Татарстанныкы булуым белән горурланам. Әгәр гаиләдә башка телдә сөйләшәләр икән, димәк, ана теленә мәхәббәт шуның кадәр генә! Безнең төп бурыч – телне саклау, аны оныкларга тапшыру. Бу – әманәт. Мактанып әйтмим, безнең балалар татар телендә матур итеп сөйләшәләр. Авылдашларым да шакката. Бу – ирем белән икебезнең тырышлык нәтиҗәсе. Балалар инглиз телендә сөйләшә башлауга, шундук туктатабыз. Өйдә, сәяхәттә бары тик татарча сөйләшәбез. Интернеттан татар әкиятләре тыңлыйбыз. Татар каналын карыйбыз. Ә кичен татар халык әкиятләрен укыйбыз. Үзебезнең тырышлык булса гына, без, телне саклап, мин – татар, дип әйтә алачакбыз.

Беренче адымнар

ТАРИХИ ВАКЫЙГА

Индус ТАҺИРОВ, ТФА академигы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының беренче, 1992–2002 еллардагы җитәкчесе

Бөтендөнья татар конгрессының барлыкка килүе чын мәгънәсендә тарихи вакыйга булды. Ул тиз арада татар милләтенең халәтен, яшәешенең төп проблемаларын күрә алырдай оешма булып өлгерде. Татарларның кайда яшәүләренә дә карамастан, аларның сулышын сизеп, бер җан, бер тән булып яши башлауларына нигез салды, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга үз өлешен кертте.

Эшчәнлегебезнең иң нәтиҗәле ысулы – башкарма комитет тарафыннан уйлап табылган һәм дөреслеген тормыш үзе раслаган күчмә утырышлар булды. Аның беренче утырышы Түбән Камада үтте. Күчмә утырышларны үткәрү, гадәти хәлгә әверелеп, милли оешмаларыбызның җирле хакимиятләр белән аңлашып яшәвенә юл ачты. Аларның берсенә махсус тукталуны кирәк дип саныйм. Ул 1998 елның 9–10 мартында Санкт-Петербургта, шәһәр губернаторы Владимир Яковлев катнашында булды. Губернатор очрашуыбызның икенче көнендә конгресс әгъзалары белән мәчеткә килде һәм анда сугыш вакытында зарарланган манараны торгызуда ярдәм итәчәген әйтте. Аның ярдәме белән Казанның иске йортлардан торган Свердлов урамы төзекләндерелде һәм шуннан соң ул Петербург урамы дип атала башлады.

Гомумән, без күп губернаторлар белән аралашып яшәдек. Саратов губернаторы Дмитрий Аяцков ярдәме белән шәһәр уртасында татар гимназиясе ачылды. Свердловск өлкәсе губернаторы Эдуард Россель ярдәме белән Урал университында татар тарихын өйрәнү лабораториясе эшли башлады. Ул конгрессның күчмә утырышында хөкүмәт әгъзалары белән тулы составта катнашты. Шунда ике якның министрлары бергә эшләү турында килешүләр төзеделәр.

Екатеринбургта, Ульяновскида, Казахстанның Чимкент шәһәрендә, Самара өлкәсенең Камышлы районында узган утырышлар шулай ук уңышлы булды. Кайбер мөһим мәсьәләләр буенча очрашулар Киев, Минск, Уфа, Әстерхан, Иваново, Төмән, Нижневартовск, Чиләбе, Пермь шәһәрләрендә дә оештырылды. Бу чараларда мәгариф, мәдәният, радио-телевидение мәсьәләләре буенча килешүләр төзелеп, кабат очрашкан вакытта аларның үтәлеше тикшерелә торган иде. Конгресс Ульяновск, Оренбург, Новосибирск, Омск губернаторлары, Удмуртия һәм Якутия президентлары белән эшлекле мөнәсәбәттә булды. БДБ илләре шәһәрләрендә оешкан дистәдән артык милли оешмалар белән элемтәдә торды.

Милли хәрәкәтнең үзенчәлеге Россия төбәкләрендә милли-мәдәни мохтарият органнары барлыкка килүдән гыйбарәт. Шунысы сөенечле: шушы автономияләр аркылы милли эшләр башына югары катлау зыялылар килде. Алар татар тормышын үстерүгә зур өлеш керттеләр.

Утыз ел күз ачып йомгандай үтте дә китте. Аны оештыручылар урынына яңа буын барлыкка килде. Алар җиңел булмаган шартларда милләтебезнең киләчәген кайгырталар. Телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу һәм ныгытуны үзләренең төп бурычы итеп саныйлар. Безнең эшебезне дәвам итәләр.

КОРЫЛТАЙДАН – КОРЫЛТАЙГА

I корылтай (19–21 июнь, 1992 ел)

Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтаена бер меңнән артык кеше җыела. Пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессы карары, дөнья халыкларына һәм дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр оешмасына мөрәҗәгать кабул ителә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп Казан дәүләт университетының кафедра мөдире, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире Индус Таһиров сайлана.

II корылтай (28–29 август, 1997 ел)

Корылтайга Россиянең алтмыштан артык төбәгеннән, ерак һәм якын чит илләрдән барлыгы 459 делегат чакырыла. Мәскәү, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Татарстан кинематографистлары берьюлы берничә документаль фильм төшерә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Индус Таһиров сайлана.

III корылтай (28–29 август, 2002 ел)

Бу корылтайда 25 ерак һәм якын чит илләрдән, Россиянең 57 төбәгеннән 562 делегат һәм мәртәбәле кунаклар катнаша. Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе итеп «Казан» милли мәдәният үзәге директоры Ринат Закиров сайлана.

IV корылтай (12–15 декабрь, 2007 ел)

Корылтай эшендә 712 делегат, 217 шәрәфле кунак катнаша. Пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессының татар халкына, Россия Президенты Владимир Путинга мөрәҗәгате, татар һәм башкорт халкына мөрәҗәгатьләре кабул ителә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Ринат Закиров сайлана.

V корылтай (6–9 декабрь, 2012 ел)

Корылтайда Татарстаннан, Россия төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән 796 делегат, 302дән артык шәрәфле кунак катнаша.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әлеге чараны үзенең интернет сайтында онлайн режимда трансляцияләүне оештыра. Пленар утырышта, татар халкының алга таба үсеш юлларын билгеләү ниятеннән, «Татар халкының этник үзенчәлеген саклау концепциясе» проекты тәкъдим ителә.

Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Ринат Закиров сайлана.

VI корылтай (2–6 август, 2017 ел)

Корылтайда Татарстаннан, Россиянең 73 төбәгеннән һәм 41 ерак һәм якын чит илләрдән 811 делегат килә. Россия Президенты Владимир Путин корылтай кунакларына котлау телеграммасы юллый. Корылтай делегатлары берничә көн буена татар телен, мәдәниятен, рухи мирасны саклау, эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләре турында сөйләшәләр.

Пленар утырышта төп вакыйга Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасын оештыру була.

VII чираттан тыш корылтай (20–21 июль, 2018 ел)

Бу корылтайның көн тәртибендә Бөтендөнья татар конгрессы уставына үзгәрешләр кертү карала. Чарада Россиянең 60 төбәгеннән – 200, чит илләрдән 25 вәкил катнаша. Корылтайның пленар утырышын Татарстан Премьер-министры Васил Шәйхразыев алып бара. Ул 2017 елда VI корылтайда кабул ителгән Милли Шура уставын теркәү барышында Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан җитешсезлекләр күрсәтелүен әйтә. Шул сәбәпле чираттан тыш корылтай үткәрергә кирәк була. Уставка төзәтмәләр кертелгәннән соң, делегатлар Милли Шура рәисе итеп Васил Шәйхразыевны сайлыйлар. Шуннан соң рәис устав нигезендә үзенең беренче урынбасары итеп Башкарма комитетның ул вакыттагы җитәкчесе Ринат Закировны билгели.

ДӨНЬЯ БЕЗГӘ КАРАП СОКЛАНСЫН

Тәэминә БИКТИМИРОВА, 1992–1997 елларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы

Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае ачылган көн һәр татар өчен зур вакыйга булды. Икенче көнне, ягъни 20 июньдә эшебез «түгәрәк өстәл»ләр янында дәвам итте. Барысы 15 секция иде. Минем өлешемә «Милләт, хатын-кыз һәм гаилә» секциясендә катнашу бәхете тиде. Җитәкчесе «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза Туфитуллова булды. Зур дулкынлану белән Актерлар йортына җыелдык. Залда иң зур хөрмәткә ия кунаклар – өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов, сөекле җырчыбыз Фәридә апа Кудашева, хөрмәтле абыстайларыбыз Рәшидә Исхакый, Сәйдә Аппакова, ерак араларны якын итеп килгән Шәмсия Апакай, Нәркиз Агиш…

Анда сөйләнгән сүзләр бүген дә хәтеремдә. «Әйдәгез, татар хатынының бөтен матур сыйфатларын бөтен дөньяга танытыйк, – дигән иде галимә Мәдинә апа Рәхимкулова. – Элек күрсәтә алган бит татар хатыны үзенең матурлыгын, гыйлем-мәгърифәтле булуын, гаиләсенең toткасы һәм балаларына оста тәрбияче булуын. Дөнья безгә карап соклансын, үрнәк итеп куйсын татар хатынын».

Секция утырышында татар хатын-кызларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген җанландыру, татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, милли гореф-гадәтләрне, йолаларны саклау, татар гаиләсенең яшәеш сферасын киңәйтү һәм аны милли рухта коруга булышлык итүгә юнәлдерелгән бер адым ясалды – Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе оештырылды. Берләшмәнең советы, идарәсе булдырылды. Урыннарда берләшмәнең бүлекчәләрен оештыру максаты куелды. Күренекле галимәбез Флора Әхмәтова-Урманче тәкъдиме белән берләшмәгә «Ак калфак» исеме бирелде.

«Ак калфак»ның үз заманында халкыбыз күңеленә кереп калырдай эшләре аз булмады. Шул җәһәттән, асылыбызга кайтыр өчен, мең еллык тарихыбызны канызга сеңдерер өчен, гаиләдә, мохитебездә хатын-кызның дәрәҗәсен күтәрү өчен оештырылган «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» кебек чараларның әһәмиятен аерым күрсәтеп үтәсем килә.

Безнең эш күбрәк йомышы төшеп килүчеләрне кабул итү, мөмкин кадәр аларга ярдәм итү һәм конгрессның төрле төбәкләрдә бүлекләрен булдыруга булышу белән бәйле иде. Бәхетебезгә, төбәкләрдә татар иҗтимагый үзәкләре оешкан һәм милләтпәрвәрләребез аларда тупланган иде. Төбәкләрдән килүчеләр төрле булган кебек, йомышлары да төрле булып, еш кына уңайсыз хәлләрдә дә кала идек. Бөтендөнья татар конгрессы булсак та, баштагы мәлдә акчабыз юк иде бит әле.

Командировкадан кайтып кермәдек, дип әйтә алам. Мин үзем Минскидан Иркутскига кадәр бөтен төбәкләрне иңләдем. Башкалар да шулай йөрде. Кулдан килгәнне дә, килмәгәнне дә эшләргә тырыштык. Барып кергән җиргә татар гадәте буенча нindидер күчтәнәч алып барасы килә иде. Әмма, әйткәнемчә, акча юк. Иваново губернаторы янына 14 сумлык курай тотып кереп, бүләк итеп чыктым. Шул хәлдән бүген дә уңайсызланып куям.

Хәзер конгресста эшләүчеләргә сокланып та, көнләшеп тә карыйм. Акчалары да бар, эшләре дә масштаблы. Тагын да шулай матур эшләре белән сөендерсеннәр иде. Тик кайберәүләрнең бу эшләргә тискәре бәя бирүләрен күреп кенә эчем поша. Хәтта Сабантуй үткәрү дә телгә начар яктан кергәли. Югыйсә бу бәйрәмебез бик югары бәяләнеп, татарларны дөньяга танытты бит. Күбрәк белгән кеше тәнкыйтьләп кенә йөрмәсен, оешмага тәкъдимнәр белән килсен иде ул. Бөтендөнья татар конгрессына да, аның матур эшләренә дә уңышлар телик.

30 ЕЛЛЫК ЮЛ

Ринат ЗАКИРОВ, 2002–2020 елларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе

Утыз ел гомер эчендә Бөтендөнья татар конгрессы зур юл үтте. Шушы чорда татар дөньясы Татарстан белән бер дулкында яшәүгә иреште. Бүген дөньяның 42 илендә, Россиянең 70тән артык төбәгендә татарның 458 милли һәм дини оешмасы эшли, үзара хезмәттәшлек итә. Кайсы гына өлкәне алма – мәгарифме, фәнме, спортмы, икътисадмы, авыл хуҗалыгымы – һәр тармакта милләттәшләребез үзләрен иң яхшы яктан күрсәтә.

2002 елда, конгрессның III корылтаенда мине башкарма комитет рәисе итеп сайладылар. Аңлавымча, безгә системалы, киң күләмле хәрәкәт кирәк иде. III корылтайда күп кенә делегатлардан татар яшьләрен милли хәрәкәткә җәлеп итү турында фикерләр яңгырады. Алар арасында чит төбәкләрдәге һәм чит илләрдәге татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларында укыту мәсьәләсе дә бар иде. Без исә киңрәк бурыч – татар дөньясындагы үзебезнең оешмаларга бәйле аерым яшьләр хәрәкәтен оештыруга алындык. Нәкъ шул вакытта махсус татар яшьләре оешмалары барлыкка килде, аларның саны 50дән артты.

Мәгариф өлкәсендә махсус программа булдыруга ирештек. Ел саен читтә яшәүче йөзләгән татар баласы республика югары уку йортларына укырга керә башлады. Бу проект чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен бигрәк тә кулай булып чыкты. Әйтик, Кытайдан чыккан 100дән артык татар яшьләре төрле елларда Казан югары уку йортларында уку бәхетенә иреште. Яшьләр белән тыгыз элемтәдә эшли башлагач, бу эшчәнлекнең төп оештыручысы кирәклеге ачыкланды. Шулай итеп, без 2004 елда беренче Бөтендөнья татар яшьләре форумын уздырдык.

Дин өлкәсендә дә шактый катлаулы проблемалар булуы ачыкланды. Иң мөһиме бердәмлек булмавы үзен нык сиздерә башлаган иде. Шуны аңлап, БТК дин әһелләрен аралаштыру өчен бер мәйданчык булдырырга алынды. «Изге Болгар җыены» дип аталган яңа чара гамәлгә куелды. Бүген инде бу чарага төрле җирләрдән меңләгән кеше килә. Төбәкләрдә татар имамнарына мохтаҗлык зур. Шуны аңлап, без Казандагы Россия Ислам институты белән дә хезмәттәшлек итә башладык.

Соңгы елларда татар тормышының иң авырткан мәсьәләсе – татар авыллары яшәеше. Кайбер татар авылларының тәҗрибәсе белән танышканнан соң, без аны башкаларга да таратырга кирәк дигән фикергә килдек. Шулай итеп, 2012 елның язында I Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре форумы узды. Шушы нигездә Бөтенроссия татар авыллары оешмасы барлыкка килде.

БТКның Сабантуй бәйрәмнәре, фольклор фестивальләре, «Татар кызы» конкурслары, җыр фестивальләре кебек мәдәният, халык традицияләренә кагылган проектлары турында да әйтеп үтәргә кирәк. Шушы чаралар нигезендә күпчелек төбәкләрдә дистәләгән иҗат коллективлары барлыкка килде. Татар халкын берләштереп торучы төп чара – Сабантуй. Чит илләрдә дә бу бәйрәмне үткәрү гадәткә керде.

Татар конгрессы өчен ул елларда Башкортстандагы татарларның мәнфәгатьләрен хәл итү иң четерекле мәсьәлә булып торды. 2002 елның декабрендә халык санын алу чарасы мәсьәләне тагын да катлауландырды. 2007 елгы IV корылтайга әзерләнгәндә, без мондый каршылыкны туктатырга кирәк дигән фикергә килдек. Нәтиҗәдә махсус мөрәҗәгать кабул ителде. Ниһаять, вазгыять шактый йомшарды: Башкортстанда Татарстан телевидениесен карый башладылар, ике республиканың иҗат коллективлары янә бер-берсенә гастрольләргә йөри башлады.

Мин җитәкчелек иткән чорда Мәскәүдә Халыкара Россия ватандашлары оешмасы барлыкка килде, безнең конгресс аны оештыручыларның берсе булды. Нәтиҗәдә Тышкы эшләр министрлыгының «Россотрудничество» оешмасы аша чит илләрдәге татарлар мәнфәгатьләрен андагы илчелекләр аша яклау мөмкинлеге ачылды. 2013 елда Европа парламенты бинасында Европа татарлары альянсының (АТА) оештыру җыелышы узды, ул җыелыштан соң әлеге оешма Бельгиядә рәсми теркәлү узды. Шуның аша андагы татарларга мәдәни чаралар уздырганда төрле халыкара оешмалар ярдәменә таяну мөмкинлеге ачылды. Конгресс эшчәнлеген илнең Тышкы эшләр министрлыгы да югары бәяли. Россия ватандашларының халыкара җыеннарында тышкы эшләр министры Сергей Лавров һәрвакыт Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеген башкаларга үрнәк итеп куя. Бу – Татарстан Республикасы өчен дә зур дәрәҗә.

БҮГЕН ВАЗГЫЯТЬ БАШКА

Разил ВӘЛИЕВ, 1992–2002 елларда Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе урынбасары, 2002–2012 елларда Мәдәният комиссиясе рәисе

Узган гасырның 80 нче елларында татар халкы арасында милли хәрәкәт активлашып китте. Халыкның милли аңы үсә башлады. Илдәге демократия җилләре аның өчен шактый гына мөмкинлекләр тудырды. Бу активлашуның кульминацион ноктасы буларак 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт бәйсезлеге турында декларация кабул ителде. Шуннан соң инде башка бик мөһим сәяси вакыйгалар да булды: Конституция кабул ителде, референдум үткәрелде. Әмма аңа кадәр, 1992 елның башында, Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең Бөтендөнья татар конгрессын оештыру турындагы фәрманы чыкты. Мондый оешма ни өчен кирәк булды? Бу хакта төрле фикерләр бар. Берәүләр аны иҗтимагый оешмаларга көндәш буларак кабул итсә, икенчеләр милли хәрәкәтнең эшчәнлеген дәүләт мөмкинлекләрен файдаланып алып баруда күрделәр. Чыннан да, иҗтимагый оешмалар үз эшләрен эшлиләр, ул заманда алар бигрәк тә актив эшләделәр. Әмма дәүләт ярдәменнән башка алга куйган зур максатларга ирешү, бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татар халкын берләштерү мөмкин түгел иде, монда дәүләтнең барлык мөмкинлекләрен дә файдалану кирәк булды.

Шулай итеп, 1992 елда конгресс оешты. Милли оешмалар да үз эшләрен дәвам иттеләр. Безнең бурычларыбыз бер, максатларыбыз уртак иде: татар халкының сәяси һәм икътисади мөмкинлекләрен арттыру, аның дәүләтчелеген ныгыту, туган телне, милли мәгарифне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау һәм башкалар. 1992 елның 19 июнендә конгрессның беренче корылтае үткәрелде. Мин корылтайларның һәрберсендә катнаштым, кайберләрендә чыгыш ясарга да, секцияләрне җитәкләргә дә туры килде. Ул чорда мөмкинлекләр башкачарак, зуррак иде. Нәкъ шул елларда милли мохтариятләр булдыру турында Россия күләмендә закон чыкты. Шуңа нигезләнеп, татар халкының да федераль дәрәҗәдәге милли автономиясе барлыкка килде. Һәм шунысы үзенчәлекле: ул елларда милли мохтарият белән конгресс берләшеп эшләделәр. Аларның икесенә бер уртак җитәкче – атаклы галим, академик Индус ага Таһиров булды. Бу бергәлекнең көче зуррак кебек тоела иде безгә. Ике көчле оешма. Аның берсе федераль закон белән расланган, икенчесе – Татарстан Президенты Указы белән. Индус ага бу мөмкинлекләрдән бик оста файдаланды. Мин ул вакытта Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары идем. Индус Таһировның эш стиле, дәлилләре, чыгышлары күңелемә һәрчак якын булды. Ул чорда читтә яшәүче милләттәшләребез янына күп йөрдек. Кайсы гына төбәккә барсак та, Индус ага иң зур җитәкчеләр белән очрашырга җай тапты. Анда яшәүче татарларның проблемаларын бик оста итеп җиткерә, фәнни дәрәҗәдә дәлилле итеп аңлата белде. 1994 елда Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләр бүлешү турында беренче шартнамә кабул ителде, монда да Индус аганың роле бик зур иде. Ул татар халкының, аның дәүләтчелегенең тарихын яхшы белә. Россия делегацияләре белән аралашкан вакытта аның саллы чыгышлары һәрчак нәтиҗәле булды.

Әйтергә кирәк, конгресс эшчәнлегенә кагылышлы традицияләр хәзер дә дәвам итә. Әмма бүген инде сәяси вазгыять тә, мөмкинлекләр дә башка. Конгрессның структурасында да үзгәрешләр булды. Элек аның башкарма комитеты гына бар иде. Хәзер карарлар чыгаручы югарырак оешмасы – Милли җыены да барлыкка килде. Ул күбрәк идеология белән шөгыльләнә, эшчәнлеккә юнәлеш бирә, стратегия документлары, концепцияләр әзерли, максатларны билгели. Башкарма комитет исә шушы Милли җыен кабул иткән карарларны тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

ӨМЕТЛӘР АКЛАНДЫ

Ренат ХАРИС, Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты

Бөтендөнья татар конгрессының идея һәм концепция авторы буларак, 30 ел элек булган хәлләр бүгенгедәй күз алдымда. Ул вакытта мин «Татарстан хәбәрләре» дип аталган парламент газетасының баш редакторы, Татарстанның Югары Советы депутаты (ул вакытта безнең парламент шулай атала иде), мандат комиссиясе рәисе идем. Казан Кремлендә, Югары Совет бинасындагы бер бүлмәдә безнең редакция коллективы әле оешып кына килә. Гаҗәеп кызыклы һәм киеренке еллар иде бу, чөнки параллель рәвештә Бөтендөнья татар конгрессы да оеша башлады. Ул дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәгән татарларны милләт, халык булып берләштереп торырга дигән ният белән төзелде. Татарстанда яшәүче татарлар дөньядагы барлык татарларның мәнфәгатен күз уңында тотып, аларга таянып, ә читтә гомер итүче милләттәшләребез безгә таянып, ярдәмләшеп гомер итәргә тиешләр. Шул чагында гына безнең киләчәгебез, язмышыбыз имин булачак.

Эш барышы болайрак булды. 1991 елның март – апрель айлары. Мин булачак оешманың концепциясен, нигезләмәсен эшләдем. Ул вакытта Дәүләт Советында аппарат җитәкчесе Хәләф Низамов иде. Документларны аңа күрсәттем. Ул мине Югары Совет рәисе Минтимер Шәрипович Шәймиев янына алып керде. Минтимер Шәрипович, гадәттәгечә, мәсьәләгә бик җитди карады, төрле яктан килеп фикер йөртте, бәхәсләште, аның нинди сәяси проблемалар тудырачагы турында ачыктан-ачык уйланды. Ул да Җир шарының төрле кыйтгаларында яшәүче татар милләтен тарихи туган җирләре белән элемтәдә тотучы көч кирәклеге турында күптән уйлана икән. Кыскасы, ул аны хуплады. «Әйдәгез, оештырабыз, моның өчен оештыру комитеты булдырырга кирәк, тиз арада исемлек китерегез», – диде. Ул вакытта Югары Советның юридик бүлеген Рәисә Сәхиева җитәкли иде. Без өчәүләп – Хәләф Низамов, Рәисә Сәхиева һәм мин – конгрессның оештыру комиссиясен төзедек, иң беренче документларының проектларын әзерләдек. Конгрессның беренче корылтае 1992 елда булды. Ул вакытта Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының Президенты иде инде.

Әйтергә кирәк, конгресс төзү идеясе тикмәгә генә тумады. Бөтен яктан да киеренке ул заманда Татарстан Конституциясен төзү буенча комиссия эшләде. Аның җитәкчесе Президентыбыз Минтимер Шәймиев иде. Мин – шул комиссия әгъзасы, «Татарстан дәүләт символлары» һәм «Республикабыз башкаласы» дигән маддәләр өчен җавап бирәм. Бу хакта соңрак китап та яздым. Ул татар, рус һәм инглиз телләрендә басылып чыкты. Төп Законны эшләү барышында республика, аның киләчәге, халкы турында уйланасың. Татарстанда татарларның 25 проценты гына яши, 75 проценты читтә гомер итә. Ә без Төп Законны кем өчен кабул итәбез? Татарстанда яшәүче татарлар өченме, әллә инде бөтен дөньяда таралып яшәүче татарлар өченме? Әлбәттә, безнең уебызча, ул бөтен татар өчен булырга тиеш иде. Татарстан Республикасы Конституциясендә соңрак «Республикада яшәүче халык, дәүләтебез Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтергә тиеш» дигән маддә дә барлыкка килде, ягъни конгресс идеясе республикабызның Төп Законы белән ныгытылды, гамәлгә кертелде.

Бөтендөнья татар конгрессын төзү турындагы указга Минтимер Шәймиев имза куйды. Без аннан: «Бу оешманың җитәкчесе сез булырга тиеш түгелме?» – дип сорадык. «Юк, – диде ул. – Минем эшем республика чикләрендә кала. Монда шундый кеше кирәк: ул бөтен татар халкына билгеле дә, теоретик яктан әзерлекле дә булсын, татарча да, русча да яхшы белсен, башка телләрне белсә дә бик әйбәт. Менә шундый абруйлы кеше эзләп табыгыз», – дип күрсәтмә бирде. Уйлый торгач, иң беренче рәис итеп академик Индус Таһировны тәкъдим иттек. Һәм бу кандидатураны беренче корылтай бертавыштан кабул итте.

«Конгресс өметләрне акладымы?» дигән сорауны еш бирәләр. Әлбәттә,аклады. Тик замана үзгәрә. Аның белән бергә конгресска да, республикага да, милләтләргә дә таләпләр үзгәрә. Шул таләпләргә җавап бирә-бирә, конгресс үзенең эшен үзгәртә торды. Иң мөһиме – татарны, республикабызны, мәдәниятебезне, тарихыбызны башка халыкларга күрсәтү-таныштыру. Әгәр халыклар бер-берсен белмәсә, бер-берсен аңламаса, дус яши алмый, ә дуслыкның булмавы илнең нигезен какшата. Аны икътисад кына саклап кала алмый. Кайда гына яшәсә дә, татар беркайчан да шул төбәктә, илдә-дәүләттә ыгы-зыгы чыгармады, матур итеп яши белде, һәм алда да шулай булачак. Безнең конгрессыбызның да төп максаты – милләтебезне берләштереп, аңа башка милләтләр арасында үзенең лаеклы урынын тотарга ярдәм итеп, Россия дәүләтчелегенең нигезен ныгыту.

ТАПШЫРЫЛСЫН ХАТЛАР

Без әле кая барабыз?

Замананың бер «чир»е безгә дә килеп җитте: моңа кадәр авылымда хат ташучылар белән проблема юк иде. Күп еллар Илдус абый Миңһаҗев эшләде, аны Фәйрүзә алыштырды. Аннан Люда, Гүзәлия, Раушания, Люция... – барысы да кешеләр белән яратып эшләде, тавыш-тын чыкканны, ризасызлык булганны ишеткән юк иде. Менә инде ярты еллап авылыбызда чынлап эшләүче хат ташучы юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Олы йортка ни кирәк – кече йортка шул кирәк», – ди халык мәкале. Хат ташучысыз да бик кыен икән...

Вакытлыча эшләп торган Гөлнар да туктады. Биш мең сум акчага (кечкенә авылларда 0,4 ставка гына түләнә) беркем дә көн саен авыл урамын урап, аена ничә кабат өй саен йөреп, түләүләр җыеп, пенсия, субсидия, почта өләшеп йөрмәс шул. Әле товар сатарга дигән планнары да бар бит.

Бездә генә түгел, җирлекнең башка авылларында да бар инде бу проблема. Күрше Биктәш белән Салавыч Сәрдегәнендә әнә авылның мәдәният йорты җитәкчеләре Гөлирә Нуриева белән Рәмзия Гарифуллина, авылдашларының хәленә кереп, өлешчә бу хезмәткә алынган. Иске Салавычта да гомер-гомергә ике бригадада ике хат ташучы булды. Менә бер елга якын инде 287 хуҗалыклы авылга Илүзә Миңнемуллина берүзе хезмәт күрсәтә. Яшь булса да, бик тырышып, аңлашып эшли дип беләм.

– Почта килер алдыннан сәгать унберләргә бүлекчәгә киләм, кичке сигездән дә иртә кайтканым юк, – ди Илүзә. – Уңайлы булсын өчен газета-журналларны авыл урамнары буенча өч өлешкә бүлеп, тәртипләп тезеп куям һәм шул тәртиптә өләшәм дә. Баштарак кыен булды, берничә ай әнием дә булышты. Хәзер ияләндем инде. Салавычта газета-журналларга бик күп язылалар. Җомга көнне авылның бер өлешенә генә өләшергә дигән газета-журналлар белән рюкзагым тула, әле кулымдагы пакетымны да шыплап тутырам. Авырсынып әйтмим, аңлап язылган авылдашларга бик рәхмәтле мин. Алар белән аңлашып-килешеп эшләгәнгә, шөкер, язылу буенча планым да, товар сату буенча планым да үтәлә. Кешеләр белән эшләгәндә һәркемнең күңеленә юл табарга тырышасың инде, олылар белән олыларча, яшьләр белән яшьләрчә сөйләшәсең. Психолог та булырга туры килә, кем уен-көлке ярата, кем бик җитди. Хәзер бөтен кешене өйрәнеп беттем дисәм дә була. Алар да миңа ияләште инде...

Өч йөзгә якын хуҗалыкның күпчелегендә пенсия яшендәге өлкәннәр бар. Ничектер шулай гадәтләнгәннәр, бездә күпләр пенсияне карта белән түгел, хат ташучылар аша ала. «Андыйлар кимеми, киресенчә, соңгы вакытта пенсиягә чыгучылар өстәлә генә бара. Түләүләрне дә Салавыч буенча бик аз кеше онлайн түли. Син кереп алгач, бик җайлы диләр», – ди Илүзә. Менә шуннан аның эш күләме аермачык күренә дә инде: бер хуҗалыкка аена әллә ничә тапкыр керергә дә кирәк (пенсия-субсидияләр бер көнне килми, шулай ук түләүләр дә). Болар гына да түгел, айга бер көн билгеләп, Сәрдегәнгә дә түләүләр җыярга менә. 50 хуҗалыклы ул авылда да аны көтеп торучылар бик күп.

Үткән җәй буе биктәшлеләр кибетсез-сатучысыз калып тилмергән иде. Эшләргә кеше булмаганлыктан, шәхси эшмәкәр кибетен ябарга мәҗбүр булды. Ярый әле, тагын бер якташ эшмәкәр, арендага алып, прилавка артына үзе басты... «Бездә дә Алсу туктаса, аның урынына керердәй кеше юк, кибетсез дә калсаң, нишләргә кирәк?!» – Авылдашлардан бу фикерне шактый ишетергә туры килә. ФАП мөдире Раушания Минһаҗева да пенсия яшендә, ул туктаса, урынына кеше табылырмы, дип тә шикләндерә... Укып-ишетеп торабыз, андый проблемасы булган авыллар да бар.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫ ЭНҖЕ ӘСӘДУЛЛИНА:

«СӨЙЛӘШҮ – БЕЛҮ ДИГӘН СҮЗ ТҮГЕЛ»

Узган атнада Дәүләт Советында Әдилә Шәйхетдинованы кунак иттеләр. Татар теленнән республика имтиханын тапшырган бердәнбер укучы ул. Без аның укытучысы, Балтач районының Норма мәктәбендә белем бирүче Энҗе ӘСӘДУЛЛИНА белән туган телне укытуда кая таба баруыбыз турында сөйләштек.

:: Туган телебезне өйрәтү өчен сәгатьләр саны җитәме?

– Татар теленә игътибар арта башлаганын сизәбез. Бу республикада тормышка ашырылучы төрле программаларда чагыла. Ләкин җитешсезлекләр дә аз түгел. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре саны җитми. Татар телен белү ул татарча сөйләшә белү дигәнне аңлатмый. Аның үзенең грамматикасы, мең еллык тарихы бар. Менә боларны өйрәтү өчен, дәресләр саны җитеп бетми. Дөрес, өстәмә шөгыльләнәбез, түгәрәкләр алып барабыз.

:: Дәреслекләр катлаулы, балалар түгел, әти-әниләр дә аңлап бетерми, дигән сүзләрне ишетәбез. Замана әсбаплары белән туган телне күңелгә сеңдерерлек итеп өйрәтеп буламы?

– Без татар мәктәпләре өчен төзелгән программа белән укытабыз. Рус телендә белем алучы балалар да бар. Әлбәттә, соңгы елларда дәреслекләр күпкә үзгәрде. 1 нче сыйныфта укыймы, әллә унберенчедәме, бала – барыбер бала инде ул. Аның күңеле уенга тартыла. Дәреслекләрне төзегән вакытта уен элементлары, картина белән бизәү отышлы. Укучыны куркыта торган булмасын. Дәрес озак үтә, дип, балалар сәгатькә карап утырырга тиеш түгел. Кызыксындыру өчен, этәргеч тә кирәк.

Мин дәрестә кагыйдә ятлатуга каршы түгел. Хәтерне яхшырта бит ул. Моның бер начар ягын да күрмим. Бер генә әйбергә аптырыйбыз без. Мәсәлән, татар теле олимпиадаларына әзерләнгән вакытта, кагыйдәләр төрле чыганакларда төрлечә языла. Кагыйдә ул бер генә төрле булырга тиеш.

:: Татар теле укыту мәсьәләсендә балалардан бигрәк, әти-әниләрнең мөнәсәбәте гаҗәп. Татар кешеләре каршы чыга үз теленә.

– Безнең сыйныфта 20 укучы бар. Дөрестән дә, әти-әниләр җыелышларында «баланың БДИ бирәсе бар, вузга укырга кергәндә, безгә кирәк түгел ул» дигән фикерләр дә яңгырый. Ләкин мин: «Татарлар, кайда гына укыса да, татар булып кала. Киләчәктә балаларын татарча тәрбияләргә туры киләчәк. Шуңа күрә татар теленең матурлыгын, тарихын аңлатырга кирәк. Тәрбия өчен, татар дөньясының киләчәге өчен кирәк бу», – дип аңлатам. Бала татар мәктәбен тәмамлый икән, ул туган телдән имтихан тапшырырга тиеш дип саныйм.

Сәрия МИФТАХОВА

Энҗе Әсәдуллина – район күләмендә 36 җиңүче, 71 призёр, республика олимпиадаларының республика этабында 26 призёр, РФ дәүләт телләре буенча мәктәп укучылары һәм студентларының бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабында 3 призёр, татар теленнән Халыкара олимпиаданың йомгаклау турында 3 призёр әзерләгән укытучы.

ЧАЛЛЫ САНДУГАЧЫ

Язмыш

Кукмара районының Адай авылында гомер итүче Фәнүзә Миңнегалиева утынын да кискән, заманында атын да җиккән, айгыр белән үгезне дә тыңлаткан, өйдәге хатын-кыз эшен дә алып барган. Адайга Түбән Кама районының Кызыл Яр авылыннан килен булып төшә ул. Кечкенәдән укытучы булырга хыялланса да, теләге чынга ашмый кала.

– Рус телен су урынына эчкән бала идем мин. Хәзер яшем җитмешкә җитеп бара инде. Тик, төнлә уятып сорасалар да, бөтен кагыйдәне беләм. Оныкларга дәрес тә әзерләтәм, – ди ул. – Мин бит Алабуга педагогия институтына укырга кергән идем. Имтиханны тапшырганда фамилиядәш кыз барлыгын белдем. Ул чакта моның миңа начар якка борыласын уйлап та карамадым. Ә ул яныма килде дә: «Миңа рәнҗи күрмә, әти белән әни мине укырга кертмәкчеләр, синең билгең минеке булачак», – диде. Аннары белештем: ул укырга килеп тә тормаган. Икенче елны имтихан биреп карыйсым калган, ә мин бармадым. Шул үкенечкә калды.

Язмыштан уза алмый Фәнүзә апа. Дус кызы, әйдә, мал табибына укыйбыз, ветеринария училищесына барыйк, дигәнгә каршы килми. Нәкъ шушында укыганда ул булачак ире белән таныша.

– Укуны тәмамлагач, ирем мине үзеннән калдырмады. Җизни белән апа озата килделәр. Җизнәм, Нургали миннән 7 яшь олы булгач, хатын аергандыр, балалы кешедер, дип шикләнде. Җыйналып, каенаналар йортына кайтып кердек. Шунда нәнә (монда каенананы шулай дип йөртәләр) үзе самавырдан чәй ясый, үзе, авылыбыз кызы булмады инде, йөрешергә кодагыйлар юк, дип сөйләнә. Яшьлек белән сүзләрен ишетмәгәнмен дә инде, – ди Фәнүзә апа.

Алар ире белән бергә колхозда эшли башлыйлар. Фәнүзә апа олы гәүдәле, көчле хатын була. Әнә шуңа бер эштән дә курыкмый ул. Сыер да бозаулата, аннан авыррак эшләрне дә башкара.

– Нургали белән икәү сыер да бозаулатабыз, үгезләр, дуңгызлар, атлар печә идек. Әле дә исемдә: «Заря» колхозында бер көнгә 20 айгыр печеп кайттык. Ул чакта миңа 21 яшь иде. Кайтып яткач кына эчкә курку керде. Маллар әрәм булмасын, дип борчылдым. Шөкер, бар да исән-сау иде, – дип искә ала Фәнүзә апа. – Баштарак читен булды. Кукмара яклары Чаллыга, Түбән Камага китә торган заман иде бит. Күрше Алан-Оштырмага мал карарга баргач, авыл кешеләре мине кызгана иде. «Чаллы сандугачы» дип йөрттеләр. Чәй эчермичә җибәрмиләр иде.

Эшкә батыр гына түгел, көчле рухлы да була Фәнүзә апа. Сагынам, дип елап утырмый, кияүгә килгәч, матур яшәргә тырыша. Кыскасы, гаиләләре тату яши, арага кеше сүзе кертмиләр. Фәнүзә апа үзе дәү әни булса да, каенанасына әле дә рәхмәтен укый.

– Каенаналар аяклы йозак бит ул, балакаем. Бергә торган чакларны әле дә сагынам. Башка чыккач, нәнәләр бездән өч өй аша гына иде. Гел бергә булдык. Нургали белән өч бала үстердек. Ике улыбызны бер айда өйләндердек. Яшь аралары ике елга да тулмый. Үзләре, бергә өйләнәбез, дип сүз куешкан булган. Каршы килмәдек инде, – ди Фәнүзә апа. – Олы улым өйләнеп, туйның икенче көнендә кулын имгәтте. Күршеләр яна башлагач, йөгереп кергән була. Уң кулының нервы өзелеп, әле дә эшләми. Шөкер, икесенең дә тормышы матур.

Фәнүзә апа гомере буе чигү чиккән. Адайга килгәч, шәл бәйләргә өйрәнә. Ир ягы туганнарының һәммәсенә ни кирәк, шуны чигә. Хәтта ике килененә мендәр тышлары, өстәл япкычлары, сөлгеләр әзерләп куя. Берәр шәл бәйләп бирә. Кызы Фирүзәне кул эшенә өйрәтеп үстерә. Кызы да, әнисе кебек, ирләр эшенә һәвәс булып үсә. Мәктәпкә киткәнче өч сыер сава, ике үгез карый. Фирүзә ат та җигеп йөри әле. Авылда килене итәргә теләүчеләр күп була аны. Әмма Фәргать исемле егет аны башка кешегә бирми.

– Кыш буе чигү чигәм. Язга чыгуга заказлар килә башлый. Безнең якларда әле дә килен сөлгесе йоласы сакланып калды. Кызлар сорап чиктерә. Мендәр тышларына да чират, – ди Фирүзә.

Сүзгә Фәнүзә апа кушыла. Кызымның тормышы шөкер итәрлек, ди ул.

– Адайдан да матур җир юк. Хәзер минем авыл шушы инде. Иремә рәхмәтлемен. Начар яшәмәдек, авыр сүз әйтмәде, – ди Фәнүзә апа. – Яратып яшим, кешеләре әйбәт. Үкенерлек итеп яшәмәдем. Тормышыбызга мең кат шөкер итәрлек.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Безнең авылда язучы яши

Безнең якларның табигате матур. Илеш турында әйтәм инде. Башкортстан бу. Минем күп вакыт уйланып та йөргәнем бар. Менә кешеләр кайларгадыр барып ял итү өчен йортлар алалар. Фәләнешәр меңгә. Ә менә минем авылымда бушлай ял итәргә мөмкин. Кышларын тау шуам дисәң, таулары бар. Болай гына чаңгыда йөрим дисәң, яланнары бар. Урманнарда йөрергә теләсәң – урманнары. Җәйләрен су керергә уйласаң, елгалары бар. Балык тотарга теләсәң дә, шул елгаларның җайлы урыннары бар. Барысы да бар, кыскасы. Бары тик шул Ходай биргән хозурлыкның кадерен белеп кенә яшә.

Күрше авыл Кадер дип атала, ул миңа ныграк ошый кебек. Бәлки сөйгән кешемнең туган җире булган өчендер. Анда – таулар. Нарат, чыршы, каен һәм төрле агачлар белән капланган таулар тезмәсе. Шуларга карап аз гына утырсаң да, әллә нинди фантазияләр калкып чыга. Үзеңне мәңгелек белән тиңдәш итеп тоясың. Тауларга карасаң, үзең дә алар шикелле тоеласың. Мәгърур булып, текә булып, горур булып...

Арырак китсәң, Карабаш авылының Иш таулары... И, авыллар буйлап санап кына бетерерлек түгел инде ул. Ходай безгә барысын да биргән. Тауларын да, урманнарын да, яланнарын да, елга-күлләрен дә.

Ләкин без егет чакта чагыштырырга тырыша торган идек, кемнең авылы матуррак дип бәхәсләшә идек. Болар да бәхәсләшкәннәр. Үрге Яркәйдәге авыл хуҗалыгы училищесында укыган малайлар инде болар. Бәхәсләшкәннәр, авылларын чагыштырып караганнар һәм шунда берсе әйтеп куйган:

– Ә безнең авылда язучы яши.

ЕГЭ балалары, яшьләр надан, дип көлсәк тә, яшьләр ул кадәр үк надан түгел бит инде. Берсе сорап куйган:

– Әкият, такмак язучылар безнең авылда да җитәрлек ул. Чын язучымы?

– Чын язучы! – дигән теге егет, туган авылының табигате белән горурланган сыман.

Ышанмаганнар...

Менә синең авылың әллә никадәр матур булырга мөмкин, матур авыллар күп булырга мөмкин... Ә язучы бөтен авылда да яшәми. Язучы халкы хәзер, гомумән, авылда яшәми бугай. Ә монда... Теге егеткә бик үк ышанып бетмәгәннәр инде, чүт кенә шыттыра дип уйлаганнар. Һәм үз авылында яшәгән чын язучыны күрсәтүен таләп иткәннәр. Ә тегенең чарасы юк... Алып килгән...

Вәт, шундый хәлләр... Мин үземнең туган авылымда ирекле ир тормышы белән яшәп ятам. Язам инде. Арыбрак китсәм, бакчага чыгып, чүп уаштырып керәм. Шуннан тагын эшкә тотынам. Озын тәнәфескә туктасам, кулга балта-пычкы алам. Яратам шундый шөгыльне, язучы булмасам, мин балта остасы булыр идемдер кебек. Кайвакыт балыкка төшеп кайтам. Әйбәт урынын табып, ашаткалап торсаң, балык эләгә. Урманнарданураштырып киләм. Анда рәхәт. Язучы ул табигать баласы бит инде, урманнар шавы аңа әнкәсенең җыры шикелле...

Мин ул көнне балыктан кайткан идем. Киемнәрне алыштырганчы дип, ихатадагы үләннәрне чабып чыктым, шуннан суган кыякларын җыйдым. Аларны турап суыткычка ташласаң, кыш буена яшел кыяк белән сыйланасың. Тәмле инде. Яратам шундыйны. Вәт, бер табак суган кыягы күтәреп кереп ятам, капка буенда ниндидер малайлар сөйләшеп тора. Машина белән килгәннәр.

– Марат абый! – дип сөрәнли авылдаш егет.

Мин алар янына киләм. Ихатага узалар.

– Кит әле, шундый язучы буламыни?! – дип пышылдый берсе. – Бу бит – настояшный авыл мужигы. Хәтта кырынмаган да...

Мин ишетмәгәнгә салышам. Әлеге мизгелдә миңа язучы булуым артык мөһим түгел. Мин язган чагымда гына язучы. Бөек язучы. Язганда шулай. Үз язмаларымны укыганда – тәнкыйтьче. Төзәтүче. Ә соңыннан күзәтүче генә. Ул бер-ике-өч... ну, ун-унбиш әсәр язганда гына аларны җитәкләп йөртеп була, әгәр син туктаусыз рәвештә язасың икән, бер әсәреңне дә аягына бастыра алмыйсың. Кирәкми дә. Әйбәт әсәр бала шикелле ул, үзе аягына баса, үзе йөреп китә, үз тормышы белән яши башлый. Ә бер табак суган кыягы күтәреп кергәндә, син бөтенләй язучы түгел. Син – гади авыл кешесе.

Боларны ияртеп кайткан егет ни өчен килүләренең сәбәбен сөйләп бирә. Мин елмайган булам. «Их, кырынып куясы калган, – дип үкенәм эчтән генә. – Матуррак киемнәр киеп йөрисе булган...» Ә теге егетләргә минем кием дә түгел, язган әсәрләр мөһим.

– «Китмик әле яшьлек иленнән» дигән җыр сезнекемени ул?

– «Гомер буйлап барам» да сезнекеме?

– «Агымсу» дамы?

Мин баш кагам.

– «Бердәнбер һәм кабатланмас» романы да сезнекемени?

– «Китап» тамы?

Берсе автограф куйдырмакчы булып, минем «Китап» романын чыгара. Икенчесе каршы төшә:

– Юк, абый, сез язучыга берничек тә охшамагансыз бит...

Теге егет минем китаптагы фотоны күрсәтә:

– Юк, охшаган ул. Точно үзе. Менә карагыз әле.

Бер мизгелгә телсез калабыз. Аларның болай кыланышы ошамый. Яратмыйм үземне танымаган, минем мин икәнемә ышанмаган кешеләрне. Шуңа болардан котылырга ашыгам.

– Егетләр, гафу итегез, тик безгә саубуллашырга вакыт бугай...

Урам якка кадәр озаткач, капканы бикләп куям. Кермәсеннәр, бимазалап йөрмәсеннәр. Кирәкми берсе дә.

Болар барыбер китәргә ашыкмый. Капка төбендә сөйләшеп утыралар. Верандага кергәндә колагыма эләгеп калган сүз минем бөтен киеренкелекне юып төшерә:

– Карале, язучы да кеше кебек икән...

Әлбәттә, кеше кебек инде мин. Каршыгызга эт яки песи, яки балык чыкса, сез аны ничек кабул итәр идегез? Мин язучы инде һәм мин кеше кебек...

– Жалкы, автограф алып булмады, – дип үкенә таныш тавыш. – Апа сораган иде...

Мин дә үкенеп куям. Язып бирәсе калган...

– Сезнең авылда язучы яши, – ди мине язучыга охшамаган дигән егет. – Күршеңдә генә...

Бу тавышта бераз соклану да, көнләшү дә чагылып киткән сыман була. Рәхәт инде шундый. Үз китабыңны яшьләрнең кулында күрү дә – шатлык. Язучыны авыл табигатенең бер өлеше итеп күрүләре дә. Без чынлап та туган як табигатенең бер өлеше бит инде, без аның бер байлыгы да бугай. Һәрхәлдә, Илешнең ни икәнен белмәгән кешеләр дә аны минем аша күз алдына китерә. Бәлки, бу иҗатчы алдануыдыр инде, тик шундый ләззәтле алдану... Үзеңне бәяләүчеләргә лаек булырга кирәктер...

Һәм мин һәрчак җылы торган мунчага юнәләм. Юынып чыгам. Кырынам. Әйбәтләп чәчләрне тарагач, көзгегә карыйм. Кыяфәт ничава гына кебек тоела.

Әйе!

Язучы яши.

Безнең авылда...



Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест



Иң матур тел!

Ана телебез – татар теле турында бихисап шигырьләр язылган, җырлар чыгарылган. Кем аларны яхшырак хәтерли икән? Белемегезне тикшерегез!

1. Равил Фәйзуллин бу шигырендә кемгә мөрәҗәгать итә?
«...! Бер хаҗәтсез кайчак
телне шундый бозып сөйлисең!»
А) И дускаем!
Б) И кардәшем!
В) И мөселман!

2. Төшеп калган сүзне тап.
«Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган ... сүзләремне».
А) асыл;
Б) матур;
В) шәһри.

3. «Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!»
Бу шигырь юлларының авторы кем?
А) Муса Җәлил;
Б) Халисә Ширмән;
В) Шәйхи Маннур.

4. Төшеп калган сүзне тап.
«Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, ... татар теле!»
А) даһи;
Б) матур;
В) батыр.

5. «Юк җирдә башка шатлыгым.
Әйтче, мин кемнән, я, ким?
Әткәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим».
Бу шигырь юлларының авторы кем?
А) Хәсән Туфан;
Б) Сибгат Хәким;
В) Габдулла Тукай.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) В; 4) В; 5) Б.

Ата-ана колагына

Бала да – шәхес

Танылган гаилә психологы, педагог, публицист Людмила ПЕТРАНОВСКАЯның бала тәрбияләү турында әйткән шәп фикерләре бар. Сәхифәне укучы әти-әниләргә дә файдага булыр алар.

1 Теләсә нинди очракта сез балагыз өчен әти-әни булып калырга тиеш. Ә әти-әни – баланы кайгыртучы.

2 Баланы гафу үтенергә өйрәтергә теләсәгез, үзегез үрнәк күрсәтегез. Бергәләп хаталарны танырга өйрәнегез.

3 Нервлары какшаган әни бала өчен телевизордан зыянлырак.

4 Балага «елама» дип кабатлаганчы, тынычландырганчы, аңа хисләрен кичерергә, кыен хәлдән чыгу юлын табарга булышыгыз.

АЙБУЛАТ ХАРИСОВ:

«БАЯН УЛ МАШИНА КЕБЕК, АНЫ ГЕЛ КАРАП ТОРЫРГА КИРӘК»

Чираттагы кунагыбыз – яшь баянчы, җырга-моңга бай егет Айбулат ХАРИСОВ. Без аның белән үзенчәлекле уен коралында уйнау, баянның нечкәлекләре һәм киләчәккә планнар турында сөйләштек.

Айбулат Харисовның шәхси архивыннан

:: Баянны тәүге тапкыр ничә яшеңдә кулга алдың?
– Минем әтием дә, әнием дә – музыкант. Икесе дә балалар сәнгать мәктәбендә укыта. Шул мәктәпкә мин дә йөрдем. Беренче сыйныфтан ук курайда уйнадым. Моңа мине әтием өйрәтте. Ә баянны беренче тапкыр кулыма 12 яшьтә алдым. Баян буенча да беренче укытучым әти булды. Хәзер мин Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә укыйм. Анда Ренат Сираҗетдин улы Галәвиев белән шөгыльләнәм. Ул бик күп еллар көллияттә укыта, үз эшенең остасы. Әтидән дә, аннан да бик күп нәрсәгә өйрәнәм.

:: Әлеге уен коралын сайлавыңда әтиеңнең роле зур, димәк. Башка уен коралында уйнарга теләр идеңме?
– Яңадан башка уен коралын сайлау мөмкинлеге булса да, мин барыбер баянны сайлар идем. Мин моңа өйрәндем инде хәзер. Әтинең дә йогынтысы көчле булгандыр. Аның кебек оста итеп баянда уйныйсым килде.

:: Киләчәктә үзеңне баянчы итеп күрәсеңме?
– Әйе. Әти дә, әни дә сәнгать кешеләре булгач, мин дә үземне бу өлкәдә күрәм.

:: Эстрадага кереп китү теләге дә бардыр?
– Әйе, андый теләк бар. Мөмкинлекләр дә бар иде, әлегә барып чыкмады. Башта укуны бетерергә кирәк. Тагын ике ел укыйсы калды. Әлегә мин төрле халыкара һәм республикакүләм конкурсларда катнашам.

:: Синеңчә, оста баянчы булу өчен нәрсә кирәк? Сәләтме, тырышлыкмы?
– Минемчә, икесе дә бик мөһим. Бәлки, тырышлык мөһимрәктер дә әле.

:: Баянчылар арасында кумирларың бармы?
– Алар бик күп. Бөтенесеннән азмы-күпме нәрсәдер булса алырга тырышам. Тик иң төп кумирым – әтием, әлбәттә.

:: Баянда уйнаудан тыш тагын нәрсәләр белән шөгыльләнәсең?
– Спорт белән шөгыльләнергә яратам. Шулай ук башка музыка уен коралларында – гармунда, курайда уйныйм.

:: Гармунда уйнау җиңелме, әллә баяндамы?
– Миңа баянда уйнау күбрәк ошый. Анда мөмкинлекләр күбрәк. Баянда өчтән алып бишкә кадәр, ә гармунда ике генә рәт бар.

:: Баян – үзенә зур игътибар да таләп итә торган корал...
– Ул машина кебек. Аны гел карап торырга кирәк. Баян температура үзгәрүдән, артык салкын яисә эсселектән көйсезләнергә мөмкин. Уйнамасаң, тик торса да көйсезләнә ул. Көллияттә без махсус зур баянда шөгыльләнәбез. Аның да үзенчәлекләре бар. Ә сәхнәдә кечерәк баян булса да ярый. Хәзер мин уйный торган баян – 15 килограмм авырлыкта. Әле аны сәхнәдә күтәреп басып та торырга кирәк бит. Бераз авырга да туры килә инде *(көлә)*.

:: Илһам чыганагың?
– Киләчәк турында уйлар.

:: Ә иң зур хыялың нинди?
– Алдынгы баянчыларның берсе булу.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Кунагыбыз турында белешмә

✓ Айбулатка – 17 яшь.
✓ Ул Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең икенче курсында укый.
✓ Баянда, гармунда, курайда уйный.
✓ Шәп баянчы булырга хыяллана.

Җен-пәри белән очрашу

Мәктәптә җен-фәлән кебек нәрсәләргә ышанмаска өйрәтсәләр дә, ышандырып кара син дәү әниләрне шүрәле, җен һәм убырның юклыгына! «Сәвит мәктәбендә укып, бозылып беттегез, Алла да юк, мулла да юк, бер әйбердән курыкмыйсыз!» – дип, сукранып тик торалар. Мин төн кунып йөргән Рәкыя әби дә нәкъ шулай. Ялгызы яшәгәч, җен-фәләннән бигрәк тә шикләнә ул. Менә бүген дә аның янына куна килдем әле. Тәмлүшкәләр белән самавыр чәе эчкәннән соң портфелемне ачып карасам – туган тел китабым өйдә онытылып калган. Өй эшен әзерләгән идем әзерләвен. Тик мәктәпкә китапсыз барырга ярамаганлыгын белгәнгә, иртән үзебезгә кереп чыгарга булдым. Иртән биш тулмас борын ук уянылды. Рәкыя әби: «Хет җиде тулсын, ачы таң белән курыкмыйча ничек кайтасың, җен-мазар килеп чыкса?» – дип, күңелгә шомлык оеткысын салып куйса да, киенүемне дәвам иттем. Пәлтә төймәләрен Тукайның «Сабыйга» шигырен сөйли-сөйли каптырам.

«Җен-фәлән дип сөйләшүләр
искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле –
шагыйранә ялган ул».

Әбиемә бөек шагыйрең бар ни дә, юк ни! Үземне генә чыгарып җибәрәсе килмичә, кара бәрхеттән тышланган кыска пәлтәсен кия башлады. Ул мыштырдаган арада, мин ишектән чыгып та йөгердем.

Апрель азагында, көннәр җылы торса да, иртәнге якта суыграк. Салкын һава чыккан уңайга, юка пәлтәм аша үтеп кереп, бөтен тәнемә «ревизия» ясарга кереште. Әллә һава салкынлыгы, әллә шикләнү хисе көчәйде, эчтән калтырата башлады. Үч иткән кебек, урамда лампочка-мазар да янмый, дөм караңгы. «Кире әйләнеп керсәм?» Җитмәсә, резин итекләрем шапылдавына йөрәк тә мерт-мерт итеп куя. Менә күрше Усман абзыйларның йорты. Абау! Безнең капка төбендә ап-ак бер нәрсә коймага сөялгән түгелме?! Шагыйрьнең: «Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк; Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк», – дигән шигырь юллары истән чыгып, «Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?» – дип язганы бөтен барлыгымны айкап алды. Шуннан аякларым җиргә «ябышып», ни алга, ни артка бармас халәткә килде. Җил исеп куйды. Ой! Теге ак әйбернең бер өлеше җиргә чүгәләде. Кайдандыр б-и-и-ик ерактан ишетелер-ишетелмәс кенә килгән эчке тавыш: «Йә син – хорафатларга ышанучы бер «слабак», йә чын пионер», – дип, алга атларга әйди. Капка төбенә якынлашам. Теге әйбер селкенеп-селкенеп куя, ләкин урыныннан кузгалмый. Шайтан алгыры нәрсә! Шулай да эчемнән «на высякий пажарный» дәү әнидән өйрәнгән догаларны кабатлыйм. «Әгүзү билләһи-минәшшәйтанир-раҗим. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим». Тагын бер адым... Һайт!

...Җен дигәнем – кичә апалар эскәмиягә пәлтәләрен пычратмаска җәеп утырган гәҗит булып чыкты! «Курыкканга куш, койрыгы белән биш» дигәндәй, караңгыда аклы гәҗит күземә җенпәри булып күренгән. Тәки Тукай абзый хаклы булып чыкты бит, әй!

Люция ӘБЛИЕВА

СУДА ЙӨЗӘ АЛАСЫҢМЫ?

Су коенганда бу кагыйдәләрне олылар да, балалар да истә тотсын иде!

Сабир СӘФӘРОВ.
Казан

МИНЕМ ҖӘЙ

Мин Балтач авылының «Ислам нуры» мәчетендә җәйге ял чарасында булдым. Лагерь белән Балтач районындагы Салавыч авылына, Арча районындагы Кырлай авылына, Балтач районындагы Яңгул авылына бардык.

Салавыч авылында пекарня урнашкан. Пекарняда безгә камыр ризыгының ничек пешүен күрсәттеләр. Кырлай авылында Габдулла Тукай яшәгән йортка бардык. Экскурсовод сөекле шагыйребез турында сөйләде.

Яңгул авылындагы фабрикада талдан урындыклар, өстәлләр ясалганын карадык.

Лагерьда күңелле булды. Миңа бик тә ошады.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 305

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+